МАРСЕЛЬ ГЫЙМАЗЕТДИНОВ

Син мине белмисең

Шигырьләр

КАЗАН ТАТАРСТАН КИТАП НӘШРИЯТЫ 1994

ТУГАН ЯКНЫҢ КИТМӘС КОШЫ

Без еш кына: «Шагыйрьлек —профессия түгел!— дибез. Бәлки бу чыннан да шулайдыр. Ләкин, алай бик гади икән, нигә соң эле көндәлек эше итеп әдәбиятка хезмәт итү юлын сайламаган, чын мәгънәсендә әдәбият хадиме, телисез икән, әдәбият корбаны булырга теләмәгән кайберәүләр дә гомерләре буена “җыру” чыгаралар? Хикмәт шунда ки: әйе, шагыйрьлек профессия түгелдер, әммә ул, ышанып әйтергә мөмкин, күңел балкышы, әйләнә тирәне үзенчә кабул итүнең гыйбрәтле бер билгесе, халәте рухиянең тәэссорат чишмәләре исән-сау икәнлеген искәртеп торучы тынгысыз кыңгырау буларак, һәркемне әсир, сәййәх итәргә сәләтле мог- җизаи бер көчтер, тылсым ияседер. Чыннан да, шигъриятнең “тозлы бал” тәмен татын караган, күкрәгендә “илһам камчысы”нын татлы эзләрен тойган кешеләр, гадәттә, аңарга — үтә дә нәзберек холыклы Ханымга — хыянәт итмиләр, дөресрәге, хыянәт итә алмыйлар. Чөнки ул синең бөтен барлыгыңны биләп ала; чөнки Иҗат — ләззәтле газап! Ф. М. Достоевский сүзләре белән әйтсәк, үз теләгең белән газап чигүдән лә бөегрәк ләззәт юк ул! Корифейлар өчеп генә түгел, ә бәлки көне буе завод-фабрикаларда яки басу-кырларда тир түгеп кайтканнан соң җан сурәтен ак кәгазьгә төшерү өчен кулына каләм алган күп, бик күп әһле иҗат өчен дә бу изге хис таныштыр дип уйлыйм.

Бүгенге татар әдәбиятын менә шушындый Иҗат эшен икенче шөгыле итеп яшәүче каләм ияләреннән башка күзалдына китерүе дә кыен. Миңа калса, алар татар әдәбияты күперен иңнәрендә күтәреп баручы үзәк баганаларга терәк булып хезмәт итәләр.

Марсель Гыймазетдинов — шундый иҗаткярләрнең берсе. «Шигырь язу минем һөнәр түгел» дисә дә, аның кулыннан каләме төшкәне юк. Ул — җир кешесе! Халык әйтмешли, ул кендеге белән җиргә берегеп үскән. Шигырьләре дә изге туган туфрактан шытып чыкканнар. Аның шигырьләре аяз иртәләр шикелле үтә күренмәле, саф, самими; авыл өйләре тәрәзәседәй якты өлгеле, ачык хисле шигырьләр дияр идем мин аларны.

Яз Кояшы җирдә.
Гөрләвекләр
Язгы ташкын булып йөгерә.
Якты көннең бизәкләрен
Алып була хәтта өлгегә...

Татарстан радиосыннан ясаган бер чыгышында ул үзенең ижаты турында фикер йөртеп болайрак дигән иде:
— Мин Менделеевск районында колхоз рәисе булып эшлим. Билгеле инде, ярты гомерем басу-кырларда үтә. Яз уянып кына килгән бер мәлдәме, яисә җәйге иртә-кичләрдәме, йә булмаса көзгә кергәчме — кырлар түренә карап уйланып торасың да, ирексездән күңелгә шатлык хисләре тула һәм үзең дә сизмәстән: «Матур бу дөнья!» — дип куясың. Мондый чакларда тормышның вак-төяк мәшәкатьләре бердән онытылып китә, иркен сулыш белән яшисе килә башлый. Һәм мнн шул уй-хисләремне, кодрәтемнән килгәнчә кәгазьгә төшереп барырга тырышам.
Ак кәгазьгә төшкән ак хисләр!.. Әйе, шундый бер мизгел өчен генә дә яшәргә ярый бу дөньяда. Марсель Гыймазетднов моны яхшы аңлап яши. Әгәр ул:

Китәсем юк сездән аерылып,
Ишетәсезме, басу-кырларым!
Гомеремне сезгә багышладым.
Сезгә булсын туар җырларым,—

дип әйтә икән, монда бернинди дә арттыру юк, бу чыннан да шулай. Шигырьләре—моның ачык дәлиле. «Гомерен басу-кырларга багышлаган шагыйрьнең» җырларына әле башаклар шавы, тургайлар моны килеп кушыла («чыксам әгәр иркен басуларга, тургай җыры чыңлый колакта»); анда «буразналар кояш назлавыннан кара икмәк кебек күперә»; кырларда аның «йөрәккәе бәйгедәге аттай җилкенә» башлый. Ул тормышның тәмен белеп яши, ул — оптимист.

...Ак томаннарга төренеп,
Тездән чык ярып кайтам.
Сагышларым — якты сагыш —
Гомеремне озайта.

Кыскасы, Марсель Гыймазетдннов бүгенге авыл тормышының бай палитралы сүрәтен тасвирларга омтыла, авыл кешесенә — игенчегә мәдхия җырлый.

Җырлый дигәннән, аның бик куп шигырьләренә төрле композиторлар тарафыннан матур-матур көйләр язылуның сере дә әнә шунда, шигырь нигезенә җыр хасиятләре салынуда түгел микән әле? Ни генә булмасын, без бүген Марсель Гыймазетднновны бик күп популяр җырлар авторы буларак беләбез. Аның «Аккош канат кагына», «Килмисең син көлеп», «Язлардан алалмыйм күземне», «Туган якның китмәс кошлары без» кебек җырлары эстрада сәхнәсеннән төшми диярлек. Шагыйрь:

Язгы күкрәү кебек,
Яздай карый көлеп —
Эреп аксын салкын кышлары.
Без — җилкенеп очкан,
Зәңгәр күкне кочкан,
Туган җирнең китмәс кошлары.
Яз ясаучы китмәс кошлары,—

дип язган иде. Амин, нәкъ менә шулай, «туган якның китмәс җырчы кошы» булып, җирдә яз ясап яшәргә язсын аңа.

Наис Гамбәр
4 апрель, 1993 ел

I. Куңел сандыгы

ЙӨРӘК ҖЫЛЫМ СЕЗГӘ

Сезнең өчен килгәндермен җиргә,
Сезнең өчен генә яшимдер.
Сезнең өчен алсу таң аттырып,
Сезнең өчен генә яшьнимдер!

Сезнең өчен йокысыз төннәрем,
Сезнең өчен айлы кичләрем.
Сезнең өчен барлык хыялларым,
Сезнең өчен кайнар хисләрем.

Яшәсәгез җирдә озак еллар,
Яшәү дәрте өстәп халкыма.
Шигырьләрем, бар йөрәк җылысын
Бирәм сезгә халкым хакына.

КАРЛАР ЯУСЫН...

Күзләр озата килде, күрәсеңме,
Безнең якка ап-ак кошларны.
Әле күптәнме соң җылы якка
Озатып калган идек кышларны.

Талгын гына мамык карлар ява,
Ак юрганга ябып кичләрне.
Язмышларга пакьлек өстәгәндәй,
Акландыра сыман хисләрне.

Ябалак карлар ява. Ястык кебек
Бер көндә бит җирне каплады.
Ак карлардан язмышыма табан
Акрын гына гүя атладым.

Шул карларда эзләр ятып калды,
Эзләремдә — сөю ялкыны.
...Карлар яусын, тик керә күрмәсен
Арабызга карлар салкыны.

ЯШЬ КЫЗЛАР КАПКА АЧА

Егетләр:

Моңсуланып кояш бата,
Кояш бата, ай калка.
Аклы ситса күлмәк кигән

Яшь кызлар ача капка.
Аерылды юлыбыз,
Кушылды бит юлыбыз.
Әйтегезче, чибәркәйләр,
Кемнең сөйгән яры сез.

Кызлар:
Авылны хуш искә манып,
Шомыртлар чәчәк ата.
Язлар килгәч, еш ачыла
Кызлы өйләрдә капка.
Аерылмасын юлыгыз,
Бергә булсын юлыбыз.
Сер генә итеп әйтәбез:
Сөйгән ярсыз әле без.

Кызлар:
Егет-кызның һушын ала —
Авыл кичләре башка.
Егетләрне кире бормас
Кызлы өйләрдә капка.
Аерылмасын юлыгыз,
Бергә үтсен юлыбыз.
Кунакка диеп килгәнсез,
Безгә кереп куныгыз.

Егетләр:
Яз көннәре бигрәк ямьле,
Җырлыйлар шушы хакта.
Кияү килергә ачылсын.
Кызлы өйләрдә капка.
Ал икән кигәнегез,
Гөл икән кигәнегез.
Ал да булсын, гөл дә булсын
Өзелеп сөйгәнегез.

Кызлар-егетләр:
Кияү булып бәхет керсен —
Телибез шушы хакта.
Хәсрәт өчен ачылмасын
Кызлы өйләрдә капка.
Ал икән кигәнегез,
Гөл икән кигәнегез.
Яздай матур, гүзәл булсын
Киләчәк көннәрегез.

КЫР КАЗЛАРЫ ОЧА ТЕЗЕЛЕШЕП

Кыр казлары җыенганнар инде
Җылы якка сәфәр чыгарга.

Зәңгәр күктән алар сәлам юллый
Соңгы тапкыр басу-кырларга.
Кыйгак-кыйгак моңсу тавышлары
Ярып үтә зәңгәр күкләрне.
Кыйгак-кыйгак дигән авазлары
Сискәндереп куя күпләрне.
Кыр казлары оча тезелешеп,
Җыр-моңнары кала бу якта.
«Кыйгак-кыйгак, аерылабыз»,— дигән
Сагышлары безнең йөрәктә.
Казлар оча, казлар китеп бара,
Ямансу да алар киткәндә.
«Онытмагыз безне, кайтырбыз»,—диләрдер,
Яшел хәтфә язлар җиткәндә.
Казлар оча. Бәлки кайберләре
Кайтмаска дип китеп барадыр,,,
...Уйлыйм шул чак, ярый синең белән
Ерак түгел, бәгырем, аралар...
...Киек казлар моңсуланып кына
Саубуллашып китеп баралар...

ШӘФКАТЬЛЕРӘК КИРӘК БУЛЫРГА

Кешеләр дә заманага карап
Кырыслана төште түгелме? —
Күңелләрдән шәфкатьлелек китеп,
Ярсу хисләр ташып түгелде,
Йөрешмибез кунакларга бер дә,
Күрешмибез мәҗлес, өйләрдә...
Җырлар да бит моңсызлана төште,
Мәгънәсезлек байтак көйләрдә.
Миһербанлык җитми әле бездә.
Шәфкатьлерәк кирәк булырга.
Шәфкатьлелек мирас булып барсын,
Без киткәч тә килер буынга.

ЯЗМЫШЫМДА КАЛДЫҢ

Очрашырга сүзләр бирештек тә,
Аерылды яшьлек юлыбыз.
Башланып та җырланалмый калды
Икәү язган моңлы җырыбыз.
Еллар узды, Гомер агышлары
Алып китте безне кайларга!
Гомер кышым килсә дә, мин кайтам
Вәгъдәләшкән яшел язларга.

Моңсу миңа. Кайда яшьлегебез?!
Туймас идек сөеп, сөелеп.
Язмышымда калдың, яшьлек дустым,
Язылмаган моңлы көй булып.

ҮРЛӘР МЕНҮ, ҮРЛӘР ТӨШҮ

Гомеремнең үрләренә мендем,
Инде аны төшеп барышым.
Хәлләр ничек, картлач, ди бер көнне
Якын гына булган танышым.

Уйланылды. Әллә чынлап инде,
Шулай итеп картлач булдыммы...
Күзле-башлы итәсе бар әле
Иң яраткан төпчек улымны.

Төшерде дус искә: зур улымның
Тып-тып басып йөргән баласын,
Һәм шаяртып алды: белсәң әгәр
Марсель була инде бабасы.

Һәм чынлап та риза инде йөз кат
Картаймыйча картлач булырга.
Сәламәтлек теләп алдым шул чак
Киленемә, өлкән улыма.

Үрләр менү авыр — бу хакыйкать,.
Ул турыда инде сөйләмим.
Гел менәргә әзер шул үрләрне
Тик төшәргә генә теләмим...

КАЙТЧЫ ЯНЫМА

Берсен-берсе күзләп,
Үскән җирне эзләп,
Кошлар кайта туган ягына.
Ара якын түгел.
Сине көтә күңел,
Кайтчы, иркәм, кайтчы яныма.

Кабат килде язлар,
Мине кем соң назлар,
Моңсуланып көткән чагында?
Йөрәк ничек түзәр,—

Ул бит өмет өзәр
Син кайтмасаң, иркәм, яныма...

Тагын китә казлар,
Күпкә түгел азга —
Җылы якта алар кышларлар.
Ара якын түгел,
Сиңа оча күңел —
Бирә алмыйм сине ятларга.

ТЫҢЛА МИНЕМ ЙӨРӘК ТИБЕШЕН

Нурга манып язган хисләремне
Әйтеп бирер сиңа җырларым,
Сандугачы, тургайлары белән
Шул җырларны җырлар кырларым.

Хисләремне тап төшерми генә
Карлыгачлар илтсен иртәдә.
Чык суында коенган нурларда
Рәхәтләнеп, бәгърем, иркәлән.

Шул пакь нурлар сөйсен чәчләреңнән,
Ләйсән яңгыр юсын битеңне.
Синнән башка тормыш булмагандай,
Синсез яшәү кыен бит инде.

Таң чыкларын ярып кил яныма,
Тыңла минем йөрәк тибешен...
...Хыялларда яшьлек елларына
Синең белән кайтып килешем...

НИГӘ СОҢЛАДЫҢ?

Соңладык бугай,соңардык бугай,
Кайларда йөрдең, сөеклем, болай?
Гомерләр узган, гомерләр узган —
Кайларда булдың, әйтче, син шулай?

Синең барлыкны, минем барлыкны
Мин дә белмәдем, син дә белмәдең,
Йөрәкләребез бер-берсен көткән —
Кайларда идең, нигә соңладың?

Очрашты күзләр, аңлашты күзләр.
Туган шатлыктан нурланды йөзләр.

Бәхетлеләр без, бәгърем, шатлыгым,—
Килгән булса да язмышта көзләр.

Көздә дә язлар була дип жырда
Җырламыйлар ла, бәхетем, тиккә.
Сине сагынып, мине сагынып,
Йөрәкләр тибә, йөрәкләр тибә...

ГОМЕРЕМНЕ НАЗЛЫ ҖЫР ИТТЕҢ

Көтмәгән да генә очраштык та,
Бар булганым беләп алдың син.
Гомерем буе эзләгәнмен икән —
Язмышыма кереп калдың син

Көтмәгәндә генә очраштык та,
Йөрәкләр дә вәгъдә бирделәр.
Серле карашларын күңелемә
Сөю уты алып килделәр.

Назлар килде шул карашлар белән.
Зәйтүн гөлем, сиңа мең рәхмәт.
Синең белән бу якты дөньяда
Яшәүләре, ихлас, бик рәхәт.

Очраштык та гомер уртасында
Язмышларны иттек бер бөтен.
Синсез яшәү моңсыз жыр булган бит
Гомеремне назлы җыр иттең.

КИТМӘС ИДЕМ

Саумы, яшьлек,
Кая барыш шулай,
Ник ашыгып узып барасын?
Әйтерсең лә ямьле язларыңны
Күралмыйча гел дә каласың.

Узма әле! Ашыгып ла узма.
Яшьлегемдә килә яшисем.
Яшьлегемдә килә сөеләсем,
Яшьлегемдә килә яшьнисем.

Китмә әле, яшьлек! Язларыңда
Тукталып кал озак гомергә...
Китмәс идем, әгәр мөмкин булса,
Унжидедән, дуслар мин бер дә...

РӘМЗИЯ

Тургайлары, сөюләре белән,
Тоясыңмы, тагын яз килә.
Иркәләвең, назларыңнан мине
Мәхрүм итә күрмә, Рәмзия.

Бу язларда зәңгәр күзләреннән
Гыйшык, бәхет, шатлык бөркелә.
Синең белән узган мизгелләрне
Онытасым юк мәңге, Рәмзия.

Серле итеп карауларың миңа —
Күңелемә яшәү, дәрт бирә.
Сөюләрең, мәхәббәтең белән
Йөрәгемдә кал син, Рәмзия.

КИТМӘ СИН

Сөйләшеп сүзләр дә бетмәгән,
Җырлыйсы җырлар да бар әле.
Китмә син, үпкәләп китмә син,
Янымда гомергә кал әле.

Сизәмсең, кошлардай ашкынып,
Сагынып яныңа киләм мин.
Күрешеп күзләр дә туймаган —
Китмә син, бәгырем, китмә син.

Китмә син йөрәкне яралап,
Әйләнеп барыбер килерсең.
Мәңгегә өзелеп сөярмен —
Китмә син, китмә син, китмә син...

ЙА ХОДАЕМ, БЕРҮК АРАЛА

Гомерләрне айлар, еллар саный,
Саный аны сәгать, минутлар.
Гомердән дә кыска ниләр бар,
Гомерләрдән озын нәрсә бар?
Шул гомернең кадерләрен белеп,
Яшәргә дә иде, яшәргә.
Гомер берәү.
Икәү түгел гомер —
Яшеннәрдәй кирәк яшьнәргә.
Ай, белмибез кадерләрен аның,
Үткәрәбез ызгыш-талашта.
Шәп яшибез кебек. Ваклыкларга
Күп гомерләр кереп адаша.

Көйләрнең дә моңы бетеп бара,
Төсләрнең дә төсе югала.
Бу дөньяга ниләр булды икән,
Ниләр булды икән, йа алла...
...Ришвәтче, бур түрәләрдән мине
Йа ходаем, берүк арала...

ТЫНГЫ БИРМӘМ

Дөреслекнең гел күзенә карап,
Күпме гомер яшим дөньяда.
Бюрократны кистем,
Ялагайны ярдым,
Ришвәтчегә көн юк мин барда.
Күпме түздем яла ягуларга,
Ябырылды алар үземә.
Куркыттылар,
Майлап карадылар,
Янадылар карап күземә.
Бирешмәдем. Түздем. Көрәшәмен.
Шул пычракны түгәм бу җирдән.
Тавышымны минем ишетерләр,
Үлгәчтен дә тирән кабердән.
Ирек бирмәм карак, ялагайга
Күз буярга, кеше таларга.
Яшен ташы булып томырылып
Тынгы бирмәм һичбер аларга.

САБАНТУЙ ХИКМӘТЛӘРЕ

Сабан туен, хезмәт туен
Ел да сагынып көтәм.
Бу бәйрәм галәмәтләрен
Мин сезгә сөйләп китәм.

Ат чаптыру — иске гадәт:
Халикъ беренче килгән.
Бүләккә тигән камытны
Ялгыш үзенә кигән.

Аргы урамның Шәйхенур
Катыкка башын тыккан.
Авызына өч тиен кабып,
Чүлмәктән ак баш чыккан.

Чүлмәк ватам дип, Фатыйма
Күтәргән озын корык.

Кыек китеп, комиссияне
Чыга язган бит кырып.

Чиләк белән су ташуда
Хәлимә алдын булган.
Ялгыш абынып киткән дә
Инешкә суга чумган.

Колга башындагы әтәч
Лотерей йоткан икән.
Нәкъ әнә шул лотерейга
«Жигули» чыга икән.

Шул сүзләрне ишеткән дә
Гали менмәкче иткән.
Колга буйлап шуып төшеп,
Җиргә үк кереп киткән.

Йөгереп килгән Габденур:
-Әтәч минеке,— дигән.
Чалбар-кулмәкләрен салып,
Шунда ук менеп киткән.

Әтәчне ачып алган да:
-Дай лотерейны,— дигән.
-Шаяра белмисең,— диеп,
Әтәч кычкырып көлгән.

Капчык белән сугышалар:
Төшәләр мәтәлешеп.
Бау белән ике җирән баш
Тартыша мүкәләшеп.

Муеннар, ай-яй, кызара
Янгын машинасыдай.
Бау тартышта җиңеп чыккан
Мари Тәкәштән Милай.

Аяклары кая киткән?
Капчык эчендә икән,—
Гыйльменисаның аягы
Тишектән чыгып киткән.

Абыналар, сөртенәләр,
Шуалар, мүкәлиләр.

Финишка тизрәк җитим, дип
Тәгәри, үрмәлиләр.

Баянчылар баян уйный,
Җырлар җырлый җырчылар.
Бик тә күркәм бәйрәм итә
Авылда колхозчылар.

Иң кызган чагы көрәшнең:
Кем калыр икән батыр?
Муенына тәкә салып,
Кем соң өенә кайтыр?!
Кабыргалар шытырдыйлар,
Ләкин итмиләр гаеп.
Нык көрәштә җиңеп чыкты
Үрнәк колхозчы Сәет.

Безнең якта сабан туйлар
Бик тә күңелле уза.
Сандугач, сыерчык, тургай
Бәйрәм җырлары суза.

Зәңгәр күкләр тыныч булсын,
Ел саен — сабан туе.
Тоташалар тынычлыкта
Җирдә һәркемнең уе.

ЕЛАМАГЫЗ, ЯМЕ, МАЛАЙЛАР...
Түбәләрдән түбәләргә йөрдек,
Киң урамнар безгә тар иде.
Безнең дә бит шук малайлар булып
Уйнап йөргән чаклар бар иде.

Карт-корының тавык кетәкләрен
Ничек кенә барлап йөрмәдек!
Яшь кызларны куркытабыз диеп,
Этләр кебек күпме өрмәдек...

Урамнарда җырлап йөри идек,
Тальян гармун тартып кичләрен.
Күрсәң иде ташып акканнарын
Шул чакларда яшьлек хисләрен.

Таралыштык, тамырдан бәйләнеп
Бергә үскән авыл яшьләре.

Кемнәр безне ил буйлап таратты,
Түгелсен дип йөрәк яшьләре

Бушап калган инде урамнар да,
Ятим йортлар тагын артканнар.
Кыяр урлап үскән малайлар да
Урта ирләр булып кайтканнар.

Түбәләрдән-түбәләргә йөргән
Шук малайлар, кая киттегез?
Җырлы урамнарны, әйтегезче,
Ниләргә соң ятим иттегез?
Кая соң сез тавык кетәкләрен
Пыр туздырып үскән малайлар?
...Күктән яшьләр тама. Сыкрап елый
Түбәләрне япкан калайлар.
Тимер булып тимер елый диеп,
Еламагыз, яме, малайлар...

ЮГАЛТМЫЙК ЯШЬЛЕКНЕҢ ХИСЛӘРЕН
И.гэ
Язмышлар чатында
Киләчәк хакында
Сөйләштек, серләштек кичләрен.
Сиңа дип сакладым,
(Тик җавап тапмадым)
Яшьлекнең саф, керсез хисләрен.

Озатып мин калдым.
Хәсрәткә ник салдың,
Хушлашып ак яулык болгадың.
Болытлы көннәрем,
Кайгылы төннәрем
Күп булды, ник янда булмадың?

Түздем мин сагышка.
Гомерем агышы,
Ах, синсез ямансу, бик кыен.
Сагыштан качарбыз,
Кочагым ачармын —
Кил миңа, бәгырем, кил, сыен.

Язмышлар чатында
Икебез хакында

Сөйләштек, серләштек кичләрен.
Беркемгә сөялмәм,
Беркемне сөялмам —
Югалтмыйк яшьлекнең хисләрен.

АҢЛАТМА СИН

Сине өзелеп сөюемне
Ничек аңлатыйм *икән?..*
Ш.Җиһангирова

Сөюеңне аңлатма син
Сүзләр белән, яшьләр белән.
Болай да син гөлләргә тиң,
Таңнарга тиң—шуны беләм.
Моңнар, җырлар кунелеңдә,
Таң нурлары — йөзләреңдә.
Яшәү, сөю чаткылары
Синең уйчан күзләреңдә.

Җырларыңдай, моңнарыңдай
Булсын гомерләрең озын.
Кемнәр генә сөймәс сине —
Киң күңелле Мөслим кызын...

БЕЗ КИЛМӘДЕК ЭЗСЕЗ КИТӘРГӘ

Шагыйрь Егор Уткин истәлегенә

Тарих үзе шаһит язмышларга,
Язмышларда кайныйм мин үзем.
Тарихларга кереп калдың, Егор,
Тарихларда яши Уткиным.

Еллар ,еллар! Нинди якыннар сез!
Еллар, еллар — нинди ераклар,
Каләмдәшем, Егор, кая син, дип
Тибә көн дә хәтта йөрәк тә.

Шигырьләре кан-йөрәктән чыгып,
Дәшеп тора сөю, тормышка.
Язмыш-язмыш, сине барсы өчен
Салыр идем нәфрәт-каргышка.

Бу дөньяда сәрхуш-эчкечеләр
Адәм булып күбрәк яшиләр.

Иртә китә җирдән Уткин кебек
Тормыш сөйгән шагыйрь кешеләр.

Шагыйрь. Уткин,
Нинди зур мәгънә бар
Кыска гына ике бу сүздә.
Оныттылар диеп уйлый күрмә —
Онытмадык. Син бит күңелдә.

Без бу яктан.
Без килгәннәр түгел!
Язмышыбыз туган төбәктә.
Җәгүр дустым, син мәңге яшәрсен
Шигырьләрең белән йөрәктә.

Сөйләп китэм, Җәгур синең турда —
Нинди уйлар белән яшәдек!
Заманасы кысан булса да без
Әйтеләсен әйттек, яшьнәдек.

Китапларың минем өстәлемдә,
Һәр көн саен алам кулыма.
Шигырьләрең яшәү дәрте өсти,
Алга дәшә арсам юлымда.

Шигырьләрең күп гасырлар буе
Күңелләрдә урын алачак.
Синең исем еллар узган саен
Йолдызлардан якты яначак.

Кайберәүләр эзсез китә җирдән,
Без килмәдек эзсез китәргә!
Килдек җиргә явызлыкны җиңеп,
Һәр минутны моң-җыр итәргә.

Һәм без, менә, сүзебездә тордык—
Җырлар бүләк иттек галәмгә.
Тыныч йокла. Эшен дәвам итәм
Очкын-ялкын барда каләмдә.

Зифа каеннарын баш ияләр,
Тургайларың — басу-кырларда.
“Туган якка бары бер юл кайта”,
Ә без һаман барыр юлларда.

ТЫҢЛАР ИДЕМ МЕҢ КАТ

Тыңлар идем мең кат шул моңнарны.
Күңелемә якын, якыннар,
Вафирәнең йөрәгеннән ашкан —
Газиз миңа, газиз ул җырлар.
Язларда гына сандугач
Бигрәк тә моңлы була.
Сандугачлардан да моңлы
Вафирә Гыйззәтуллина.
Җырлап узсаң әгәр гомер юлын,
Картаймассың, күпме яшәмә.
Синең җырлар, дустым Вафирәкәй,
Юлдаш булсын безнең яшьләргә.
Язларда гына сандугач
Бигрәк тә моңлы була.
Сандугачлардан да моңлы
Вафира Гыйззәтуллина.
Сандугачлар сайрый яз, җәйләрдә —
Син сайрыйсың гомер буена.
Кайда гына яшәсәм дә, җырың
Һәрчак булыр минем уемда.
Язларда гына сандугач
Бигрәк тә моңлы була.
Сандугачлардан да моңлы
Вафирә Гыйззәтуллина .

ОНЫТТЫҢМЫ ӘЛЛӘ?

Оныттыңмы әллә яшәвемне —
Ник килми соң хәбәр-хатларың?
Синең алда бармы бер гаебем,
Намусымны әллә тапладым?
Бүләк иттем сиңа яшьлегемне,
Синнән якын ярлар тапмадым.
Мин барлыкны әллә оныттыңмы —
Ник килмисең, бәгырем, яныма?
Сине сагынып сарыларга сардым,
Саргаюдан калды җан гына.
Ядкарь иттем яздай яшьлегемне
Күңелкәем сине сагына.
Барлыгымны оныттыңмы әллә? —
Килер идең шулай булмаса...
...Без йөрегән яшьлек сукмакларын
Салмак кына салкын кар баса...
Умырзая булып калыкырмын
Гомер юлларыңда һәр язда

ИСЕҢДӘМЕ?

Исеңдәме алсу нурга чумган
Таң суында битен юганың?
Мәнгелеккә таянычым бул, дип,
Иңнәремә кулын куйганың.

Исеңдәме, таң чыкларын ярып,
Дулкыннардан шашып килгәнең.
Озын толымнарың артка ташлап,
Чишмәләрдәй челтерәп көлгәнен.

Исеңдәме, бергә булыйк, дидең,
Таң җилләре назлап искәндә.
Бәхет дәрьясында йөзик, дидең,
Гомер күперләрен кичкәндә.

Исеңдәме..

АЛИЯ

Иртән таңнар зәңгәрсу булалар,
Ал кояшта алар ал димә.
Моңсуланган, ямансулаганда
Таңнар белән кил син, Алия.

Күңелләрдә назлы җырлар туа,
Таңнардан соң якты көн килә.
Шул таңнардан өзелеп көтәм сине
Таңнар белән кил син, Алия.

Юксынамын. Син торган яклардан
Сөюләрең булып наз килә.
Аңла инде: көтәм, көтәм сине —
Таңнар белән кил син, Алия.

АК ТӨЙМӘЛӘР ТАКТЫМ

Ак төймәләр тактым, бигрәк матур,
Килешә лә кара күлмәктә.
Таң сулары эчеп үскәнгәме —
Кызлар гүзәл безнең төбәктә.

Кара күлмәк. Киек каз юлыдай,
Ак сәдәфләр тора тезелеп.
Очрашулар ник соң сирәгәйде,
Еш күрешә идек без элек.

Арабызда булган мәхәббәтне
Сүрелдерә күрмик, сөеклем.
Каз юлыдай ак сәдәфләр таккан
Күлмәгемне киеп килермен.

СӨЮЕҢӘ ШАШЫП БАРАСЫҢ

Моңсуланып ник карап торасың,
Сагындыңмы әллә, матурым?
Моңсуланма, юксынма да, яме,
Сиңа сөю алып кайтырмын.
Сагынмыйдыр дисеңме син әллә,
Сагынмыйча юк һич чаралар.
Сагышларга бер дә сармас идем,
Якын булса әгәр аралар.

Шул кадәрле өзелеп сөймә инде,
Соңыннан бит булыр, аһ, кыен.
Тиң булсак та, язмышлар бит башка —
Яратулар түгел һич уен.

Моңсуланып карап торма әле,
Кавышуның тап бер чарасын...
Язмышларны җиңеп, аккошлардай,
Сөюеңә шашып барасың...

ХЫЯЛЛАР

.. Уйлар, уйлар.
Башка гел ял юк бит –
Ниләр генә килим уйларга...
Алып китә нәни балачакка
Бәйрәм итә сабантуйларда.

Яшьлегемә инде ничә кабат
Бик тиз генә килә әйләнеп.
Алсу-сары көзләремә кайтам,
Каршы алам тагын җәйләрем.

Язларымда булмый озак торып –
Яшьлек кебек бик тиз ашкына.
Хыяллардан бары алып чыга
Алсу битле ап-ак кыш кына.

Уйлар, уйлар...
Йөгерек, матур уйлар
Алып китә татлы мизгелгә.

Хыялларда канат җәя-җәя
Очабыз күк бары без генә.

Йолдызларга барып җитәбез дә
Әй, кайтабыз Җиргә кабаттан...
...Хыялларда кат-кат яшәп була –
Чынбарлыкта булмый кабатлап.

КИРЕ БОРМА, ТУГАН АВЫЛЫМ

Шактый гомер үткәч,
Илле яшем җиткәч,
Кайттым сиңа, туган авылым.
Тик шулай да
Синең өчен генә
Сабый улың булып калырмын.

Күп йөрелде читтә,
Булдың һәрчак истә —
Сагышларга юктыр бер чара.
Хәтфә урамнарың,
Җырлы урманнарың
Дәшәләр гел сабый чакларга.

Күп газаплар күргәч,
Чәчләргә чал кергәч,
Җиңеп чыгып җилен-давылын,
Сиңа кире кайттым,
Басу капкаң кактым —
Кире борма, туган авылым.

МИН ЧӘЧӘКЛӘР ӨЗМИМ

Мин чәчәкләр өзмим шау язларда,
Көзләрдә дә өзмим , үссеннәр.
Сөюләрем шау чәчәкләр булып
Йөрәгеңә синең күчсеннәр.

Мин чәчәкләр өзмим бүләккә дип,
Киң болыннар бүләк итәрмен.
Болыннардай иркен күңелеңдә
Чәчәкләрдәй шаулап үсәрмен.

Мин чәчәкләр өзмим, яшәсеннәр,
Коенсыннар таңда чыкларда.
Чәчкә түгел, мин җыр бүләк итәм.
Дусларыма кирәк чакларда.

Мин чәчәкләр өзмим, гашыйкларга
Сөюләрем белән килермен.
Кирәк икән – чәчкә урынына
Йөрәгемне алып бирермен.

БЕЛМӘДЕМ ШУЛ

Сабый чакта кыяр, кишер, шалкан
Түтәлләрен «әрчеп» тилмерттем.
Мәчесенә агач, ташлар аттым,
Этләрен дә кыйнап өрдерттем.

Бала чакта тәрәзенә көйләп,
Җепләр тартып, кадак чирттердем.
Чәче озын, урыс, дип әйтсен дип,
Такыр башка чәч тә җиткердем.

Ул казлары, үрдәк, тавыклары
Минем кулдан күпме үтмәде.
Кәҗәсенең койрыгын бордым,
Басар өчен булган үпкәне.

Кыерсыттым, толымыннан тартып,
Миңсарасын күпме чырлаттым.
Камилләрен өй-почмакка кысып,
— Мин юләр,— дип, күпме җырлаттым.
—
Сәет абзый тыйтак-тыйтак килеп,
Күпме минем арттан кумады.
Әгәр тота калса, шәрә артны
Кычытканлап күпме умады.

Белмәдем шул Миңсара кызының
Хәләл жефет — хатыным буласын.
Егет булгач, үткәнгә үч итеп,
Сүтмәс идем мунча бурасын.

Сәет абзый миңа бабай булды,
Чөкердәшеп хәзер торабыз.
Тугыз бала Сарам алып кайтты,
Унынчыга нигез корабыз.

Балачакның барлык шуклыкларын
Изге хатирә күк сакладым.
Гел төзәлеп беттем,

Сәет картның
Ышанычын гел дә акладым.

КАЙТЫР ӘЛЕ, КАЙТЫР АККОШЛАР

Сизәсеңме, көз айлары үтте,
Килеп җитте инде ак кышлар.
Моңсуланып китеп барсалар да,
Кайтыр әле, кайтыр аккошлар.

Бураннары, суыклары белән
Узып китәр тиздән ак кышлар.
Шаулы язлар җиткәч, гөрелдәшеп,
Каптыр әле, кайтыр аккошлар.

Ерак-еракларда сизмәсләр дә,
Юк, аларга тимәс ак кышлар.
Язмышлары безнең якларда бит —
Кайтыр әле, кайтыр аккошлар.

САГЫШЛАРЫМ ТУГАН ЯКТА

Венер Мөхәммәдиев музыкасы

Туган якны кем сагынмый, кем юксынмый,
Шул якларга өзелеп карап кем үксеми.
Көн дә кайтам уйларымда туган якка,
Моңнарымны көйгә салам синең хакта.

Кайтыгыз, дип пышылдыйлар
Хәтта үләннәр,
Туган якка барыбер кайта
Читтә йөргәннәр.

Сагыш утларында янам, туган ягым,
Синең турда җырлар җырлыйм менә тагын.
Йөрәк җырларымны илтсен сиңа җилләр,
Сагындыра икән, дуслар, туган җирләр.

Кайтыгыз,дип пышылдыйлар
Хәтта үләннәр.
Туган якка барыбер кайта
Читтә йөргәннәр.

Таралганбыз дөнья буйлап бәхет эзләп,
Җыйналышыйк, көтә безне туган төбәк.
Тик бәхетле була кеше туган якта —

Аңладым мин чит җирләрдә шушы хакта.

Сагышларга, сагнуларга,
Дуслар, түзмәдем.
Кайтып киләм, кабул итсә,
Туган җирләрем.

КАЕННАРГА САРГАН МӘХӘББӘТЕМ

Венер Мөхәммәдиев музыкасы

Карадың да сирпеп, үзәкләрне өзде
Сөю тулы моңсу күзләрең.
Каеннарга сарган мәхәббәтем
Өзелеп көтә сине, гүзәлем.

Бергә булган назлы айды кичләр
Чыкмыйлар шул бер дә исемнән.
Сиңа диеп моңлы бер җыр яздым
Сәйләннәрдәй тезеп хисемнән.

Шул хисләрем алып килде мине
Син гүзәлем торган якларга.
Вәгъдәләшик бер дә аерылмаска,
Сөюләрне мәңге сакларга.

КЕЧЕ ТҮРӘ УЙЛЫЙ БЕЛӘ

(Сер итеп кенә)

Гел дә үзен яхшы күрсәтергә
Ниләр генә итми нәчәлник:
Кочаклый ул, анекдотлар сөйли
Көлә кеше, әйтми начар дип,

Кызык хәлләр сибә,
Нахал сүзләр белән.
Аракы да җыеп эчерә.
Кай түрәләр начар эшләсә дә
Кыңгыр эшләрен дә кичерә.

Нинди әйбәт олуг җитәкчебез,
Нинди рәхәт безгә замана.
Бер типтереп калыйк,
Мондый түрә
Кайчан булыр безнең заманда.

Аңлар халык.
Әмма узган булыр —
Зато матур яшәп калабыз...
Стаканлап халык онын алса,
Стаканлап коньяк салабыз.

Урманнарда тәгәрәшеп эчкәч,
«УАЗ»ларда өйгә илтәләр.
Ике-өч көн ял итеп алабыз —
Түрәләр дә бит ял итәләр.

Эше качмас, куян түгел ләса,
Күпме шулай яшәп калырбыз.
Юк, мәңгелек түгел түрәләр дә -
Шешә җыеп һәйкәл салырбыз.

БЕРӘҮГӘ

Язам әле.
Язам-сызам көн дә.
Шигырьләрем никтер бик коры.
Әллә инде үзәкләргә үтә
Замананың кырыс бу чоры.

Башта йөри төрле-төрле уйлар,
Ниләр килми кеше башына.
Күңелкәйләр йомшак, керсез иде —
Әйләнде бит мунча ташына.

Дөньяларда кояш бер һәркемгә,
Яңгыры да ява бу җиргә.
Чыдап була әле эссесенә,
Түзәр идек әле жиленә.

Әмма инде түзәр хәлләр калмый,
Кешеләрнең күңеле каралса.
Адәмнәрнең йөрәген йомшартырга
Бер җылы сүз җитә ләбаса.

Бер җылы сүз, бары җылы караш
Кешеләрне күккә күтәрә.
Үзең өчен генә син яшисең икән,
Кеше, аңла, күңелең күгәрә.

Үз-үзеңне бер даһига санап,

Күккә чөйсәң әгәр борының.
Күпкә түгел синең бөеклегең,
Сни кешесе түгел бу җирнең.

ГҮЯ КҮРӘМ СИНЕҢ МОҢНАРНЫ
Гүя минем күзләремә карап,
Мең сорауга җавап эзлисең.
Сагынасың. Сызып эчтән генә
Көн итәсең, нигә килмисен?
Башларыңны артка таба ташлап,
Бәхет чәчеп нигә көлмисең?

Гүя күрәм синең моңнарыңны,
Юк, моңайма, мин бит синеке.
Нинди генә булма: усал, яхшымы син
Бәхетем син, барбер минеке.
Уйларыңны миннән яшермәче —
Ул уйлар да уртак — безнеке.

Уйланыла. Гомеркәйләр уза.
Бергә-бергә бәйлик чәчләрне.
Искә алыйк аттырган таңнарны,
Бергә узган назлы кичләрне,
Гомер кыска. Бер сагышлы уй да
Уйлый күрмә, бәгырем, син яме...

...Бәхет теләп сызылып таңнар ата,
Шул таңнарда кушыйк хисләрне.
Ядкарь итеп саклыйк әле, дустым,
Бәхет бүләк иткән кичләрне.

Чамалап ач авызыңны –
Очып китәр сүзең.
Бөтен гомерләрең буе
Үкенерсең үзең.

БАШ
Уйларымның чикләре юк,
Ниләр генә уйламый баш!
Җаны булса, шул уйлардан
Шартлар иде таш булып таш.
Кешедә булганга күрә,
Баш җәһәннәмдә дә түзә.

БОЛЫНДА
Яшь балалар бөтен тирә-ягым,
Шау-гөр килә уйсу болынлык.
Зәңгәр күгем сабый күңеледәй,
Шундый сап-саф, чиста, болыт юк.

Шатланыша, уйный бала-чага
Келәм төсле хәтфә үләндә
Кошлар моңын, сабыйлар җырлавын
Тыңлап торам тыным бүләм дә

Кайгы-хәсрәт күрә күрмәсеннәр
Шундый теләк били җанымны.
... Үкси күңел, искә алган саен
Ятим үткән бала чагымны...

ЫШАН
Син борчылма күрешмәбез диеп,
Үртәмә син, бәгърем, җаныңны.
Синең белән бергә булсын диеп,
Калдырамын ярты җанымны.

Син борчылма күрешмәбез диеп,
Күрешербез, ышан, ышанам.
Онытыр ул сине, уйламас, дисәләр
Ул сүзләргә һич тә ышанма.

Син борчылма, бәлки, очрашырбыз,
Безнеке бит әле дөньялар.
Изге җирдә сөю, сөелү бар,
Өзелеп көткән безнең җаннар бар.

Син борчылма күрешмәбез диеп,
Күрешербез. Ышан. Ышанам...

БОЛЫННАРЫМ
(Сагышларым)
Йөри идек айкап болыннарны.
Күпме гасыр шулай йөрелгән.
Печән чаптык, көттек малкайларын,
Рәхәтләнеп шунда сөелгән.

Болыннарым яшел келәм нде.
Күлләрең бай балык, җәнлеккә.
Тирә-ягың оҗмахка тиң иде.
Ул байлыклар — бары җәннәттә.

Гасырларга саклап килдең болын,
Яшь кызларның сөю җырларын.
Егетләр дә аны отып алган
Урган чакта иген кырларын.

Болыннарым, иксез-чиксез идең,
Бар тирә-як синнән туенды.
Печән чапты, җиләк-җимеш җыйды,
Һәр кешегә ачтың куеның.

Сыендырдың адәм балаларын,
Җил-яңгырдан саклап куышларда.
Киек җәнлек синдә бишек тапты,
Оя корды барча кошлар да.

Күл буйлары шаулап тора иде,
Яшь кызларның моңлы җырына.
...Бүген анда айкап йөри бары
Су өстендә шыксыз җил генә.

“Совет иле матур ил”, дип җырлап,
Туктаттылар буып Чулманны.
Моның ише явыз вәхшилеккә,
Белмим, бүтән галәм чыдармы.

Җир-планета туктагандай булды –
Әйтерсең лә, гел дә әйләнми.
Су астында калды болыннарым,
Идел басты безнең җәйләүне.

Йөзәрләгән авыллар да китте -
Су астында калды нигезләр.
Вафатларның сөякләре акты
Чулман-Идел койган диңгезгә.

Күпме байлык.Сулар ялмап алды.
Ильич уты, имеш, бирәләр.
Татар, Башкорт җирен бастырдылар
Өстә торган урыс түрәләр.

Шул мисезләр упкынгача илне
Ур-ра, диеп илтеп җиткерде.
Җан иясе ач-ялангач калды,
Олы йортка юньл керде.

Хәсрәт җиле айкый тирә-юньне,
Ачлык җиле исә як-яктан.
Болыннарым, синсез яшәү кыен,
Күнегелгән сезгә яшь чактан.

Болыннарым су астында үкси,
Ишетелә миңа моңнары.
Тыңла әле син дә, шул моңнардай
Йөрәк үөзгеч тагын моң бармы?

Үкси болын. Сыкрап йөрәк җылый
Кешеләрнең юньсез эшенә.
Болыннарда үткән гомерләрем,
Әйтерсең лә , бары төш кенә.

Кире кайтмас инде ул хозурлык
Буа шартлап, суы китсә дә.
Күлләр булмас, җиләк-җимеш уңмас
Йөз гасырлар җирдә үтсә дә.

Болыннарым, хәтфә келәм идең ,
Бай идең син җәнлек, кошларга.
Җимешкә бай, печәнгә бай идең
Малкайларга кышлар кышларга.

Хушлашамын болыннарым белән...
Күп кирәкми мине аңларга...
Кем бастырткан болыннарны суга-
Бәддогалар төшсен аларга...

БУРЫЧЛЫ ҮЛМӘС

Әҗәл килгән мине алырга,
Сыртым белән гүргә салырга.
-Бирәчәкләр күп, дим, бирәсе,
Килми әле гүргә керәсе.

-Тизрәк бир, ди, бирәсен, -
Ашыктыра мине, күрәсең.
Бурычы бар – җирдә һич үлмәс,
Ул көнемне әҗәл һич күрмәс.

Шуның өчен батам бурычка,
Сиңа киңәш итәм бер очтан.
Ал кредит, яшә, курыкма –
Әҗәл тими, болай куркыта.

АВЫЛЫМ УРАМНАРЫ

Көтү кайтты. Тынды күптән
Мал-туарлар тавышы.
Су буенда егет-кызлар
Сагынышып кавышты.
Бәхетлеләр серләшүен
Тын калып тирәк тыңлый.
Сөю-сөелу хакында
Ашкынып йөрәк җырлый.

Җырлар туа күңелләрдә,
Күңелләрдә моң туа.
Тыныч кичтә авылларга
Сөю хисләре тула.

Тынып кала инешләр дә,
Селкенми яфраклар да.
Җилләре дә ялга киткән
Еракка, офыкларга.

Аксыл төтен күтәрелә
Торбалардан өйләрнең.
Авыл тынлыгы турында
Бер туктамый сөйләрмен.

Тын кала авыл мизгелгә,
Тын кала тирә-ягым.
Шул тынлыкларны сагынып,
Бер дәртләнеп җырлармын.

Бу тынлык күңелгә якын —
Яшәү-тормыш һәр өйдә.
Тальян моңы таралачак,
Яшьләр кушылыр көйгә.

Авыллар моңсыз калмасын,
Авыллар җырлап торсын.
Җырлы-моңлы авылларда
Яшьләр тормышын корсын.

Җырлар тусын күңелләрдә,
Күңелләрдә моң тусын.
Тыныч кичтә авылларга
Җыр, тальян моңы тулсын.

КАРЛАР ЯВА

Карлар ява, ап-ак каралар ява,
Бөтерелә талгын җилләрдә.
Нәкъ илленче кышка кердем инде
Туып-үскән изге җирләрдә.

Карлар ява, мамык каралр ява.
Күмеләләр синең эзләрең.
Шул эзләрне көйдереп ятып калды
Сыю тулы кайнар хисләрең.

Карлар ява, Һәр кыш ява алар –
Йөррәкләргә төшеп эриләр.
Шул кышларга синең чакыруың:
Кышлар белән, бәгърем, кил, диләр.

Очып киләм ап-ак кышлар белән,
Тик, сөеклем, сине табалмыйм...
...Төштә икән. Төшләрдә дә елыйм –
Сөям икән сине һаман мин.

ҖАН ӨРДЕҢ СИН

Җан өрдең син миңа, җан өрдең син
Күпме гомер узган-онтылган.
Яшәгәнмен мин дә яшим диеп,—
Бәхетемә күпме омтылган.

Эзләгәнмен. Үзем дә белмәдем
Эзләгәнен тиңен күңелем.
Очраттым мин сине юлларымда,
Кайгы-сагышларым түгелде.

Җан өрдең син, яшәү дәрте бирдең,
Дистә яшькә гүя яшәрдем.
Яшәгәнмен мин дә яшим диеп,
Хәзер инде беләм, яшәрмен.

УРАП КИЛДЕМ УРАМНАРНЫ

Ялгыз гына җилләр айкап йөри
Бушап калган авыл урамын.
Әрем үскән, йортсыз нигезләрне
Ничә кабат инде урадым.

Барлап чыктым нигез хуҗаларын,
Онтылмаган алар, юк, һич тә.
Сәрби әби капкасы төбендә
Кызын үпкән идем бер кичтә.

Һәрбер йортта яшь-җилкенчәк иде,
Кызлы, уллы өйләр күп иде.
Шаулап-гөрләп торган ул зур авыл
Бүген менә җирдә юк инде.

Нинди моңсу минем күңелемә,
Яшисем лә килми бу җирдә
-Әй, кешеләр, нигә яшисез? – дип,
Сорый кебек шыксыз ач җил дә.

...Урап килдем буш урамнар буйлап –
Әрем, кылган суза үз көен.
Бик күпләр бит илләр буйлап йөри
Ач җилләрдәй эзләп үз өен...

НИКТЕР КЕРМИ КҮЗГӘ ЙОКЫ

Никтер күзгә керми йокы,
Төннәремдә уянамын.
Күзләремне ачмый ятам,
Ни өчендер уйланамын.

Җилләр исә, күктә болыт,
Ай күренми, тормый балкып.
Яңгыры да елап ява,
Гамьсезләнеп калган дөнья.

Никтер керми күзгә йокы,
Гел уянам төннәремдә.
Әллә нинди уйлар башта,
Шуңа төссез көннәрем дә.

Һай, болгана бөтен дөнья,

Йөрәк сыкрый, йөрәк яна.
Шуңадырмы, төннәремдә
Йокы керми күзләремә,
Йокы керми күзләремә...

ЧӘЧКӘ

(Әлмәт кызына)

Зәңгәр күк читендә ал кояш
Нурларын җирләргә мул чәчкән.
Шул кояш нурына манчылып,
Уйланып килә бит шук Чәчкә.

Дустанә шаяра, шаярта,
Уйлансаң, уйларны тарата.
Әйт әле, гүзәлкәй, әйт әле.
Күңелең кемне соң ярата?

Кем өчен дөньяга килдең син?
Кем өчен назланып үстең соң?
Кемнәрнең йөрәген телгәләп,
Күңеленә мәңгегә салдың моң?

Кемнәрне утларда яндырдың,
Кемнәрне чәченнән назладың?
Хисләрең кемнәргә бирдең соң
Ашкынып килгәндә язларың?

Сөйкемле, гүзәл дә син, Чәчкә!
Кемгә дә тиңләргә юк хакым.
Үреләм, алалмыйм кочакка —
Аралар булса да бик якын...

Ярый ла күңелләр саф калды...
Рухыңны төшермә һич, Чәчкә.
Вакыт ул — шифалы бер дару:
Көт, килер сөйгәнең, көт, Чәчкә.

ГОМЕР-ГОМЕРГӘ

Чишмәләрдән су алганда
Карамыйм суларына.
Син генә сәбәпче, иркәм,
Йөзем сулуларына.

Нигә генә сөйдем икән
Шомырттай күзләреңне?

Гомер буе онтасым юк
Ягымлы сүзләреңне.

Өзелеп сөям, янам, көям,
Күңлемне аңламыйсың.
Ышанмыйм сөюеңә, дип,
Йөрәгем яралыйсың.

Чишмәләрдән сулар эчтем,
Тоймадым салкыннарын.
Син генә баса аласың
Йөрәгем ялкыннарын.
Шуның өчен, сөйгән ярым,
Кавышыйк, булыйк бергә.
Иң бәхетле парлар бит без
Гомер, гомер, гомергә.

САГЫНУГА ТҮЗСЕН ҖАН ГЫНА
Җилләр белән җырың гына килә.
Ул моңнар бит үзең түгелләр.
Бер-беребезне көтеп һәм саргаеп,
Үтәр микәнни соң гомерләр.

Еракта син, тик шулай булса да,
Әйтерсең лә минем янымда.
Сагынам сине, аңла, аңла инде —
Сагышларга түзсен җан гына...

.. Бездә инде тәңкә карлар ява,
Сездә дә бит шулай явадыр.
Очрашырбыз, бәлки, көздә, җәйдә,
Көтәбезме кавышу язларын.

Бәгырькәем, барсын диеп сиңа
Сагыш тулы җырлар язамын.
Бергә кичерербез, кавышалсак,
Булган шатлык, булган газабын.

КЕМНӘР АҢЛАР
Салмак кына сары төсләр иңә
Авылларга, болын-кырларга.
Тыңла әле, басу-кырлар тынган,
Язын чумар тагын җырларга.

Көмеш күлләр карала төшкәннәр,

Җилләр тарый камыш чәчләрен.
Моңсуланып калган киң урамнар,
Ник күренми яшьләр кичләрен?

Китеп барган алар калаларга,
Карт-корылар гына авылда.
Яшәүләре, тормыш итүләре
Өлкәннәргә бигрәк авыр ла.

Яшьләрнең эш әйбәт.
Шимбә саен буш кул белән кайта -җиңел бит.
Якшәмбедә капчыкларга тулган
Бәрәнгесе, суган, калҗа-ит...
Шулай ннде...
Сары төсләр иңә авылларга,
Карт-корылар көтә язмышын.
Күпме гомер кирәк төзәтергә
Түрәләрнең юньсез ялгышын.

Авылларны терелтәсе иде,
Терелтәсе иде җаннарны...
Сары төсләр иңә авылларга,
Кемнәр генә аңлар аларны...

БЕТӘР ӘЛЕ САГЫШЛАРЫМ

Сагышларга бер чик булыр инде,
Ә беразга, бәлки, түзәрбез.
Без кайтырбыз тиздән. Урамнардан
Тальян гармун тартып үтәрбез.

Тальян моңы онытылган күптән,
Гармун моңы ят шул күпләргә.
Их, бергәләп җырлап үтик әле,
Сагыш-моңнар ашсын күкләргә.

Авылларга иңсен таныш моңнар,
Кешеләрдә хисләр уянсын.
Карт-корылар үткән яшьлекләрен
Исләренә алып уйлансын.

Аларның да яшьлекләре булган,
Тальян моңы тансык күңелгә.
Их, бер җырлап урамнардан үтсәк,
Давыл кубар кебек күңелдә.

Сагышлар да берчак бетәр әле,
Берникадәр әле түзәрбез..,
...Яшәртергә — зур теләкләр белән
Авылыбызга кайттык, күрәсез...

САЛАВАТ КҮПЕРЕ
Салават күпере чыга,
Кояшлы яңгыр яугач.
Гомеребез бергә үтсен—
Син яфрак бул, мин —агач.

Салават күпере биек,
Биек булса да менәм.
Синнән башка анда менмәм,
Алырмын үзем белән.

Салават күпере буйлап
Үтәрбез икәү бергә.
Йөрәкне йөрәккә кушып,
Яшәргә язсын безгә.

Салават күпере була
Сары, яшел, зәңгәр, ал.
Яшьлек — салават күпере,
Узып китәр, сөеп кал.

БОНДЮГ ВАЛЬСЫ
Бондюгым — иң гүзәл җирем,
Иң матур хыялларым.
Моң булып ташыган хисләр
Күңелемә сыялмады.
К у ш ы м т а:
Бондюгым — гүзәл калам,
Бәхетләр теләп калам.
Сине чынлап сөюемне
Иң матур җырга салам.

Тын тауларны килеп үбә
 Чулманның дулкыннары.
Яңара борынгы төбәк
Яңара туган ягым.
Кушымта.
Киләчәк буыннар әле
Шатланып монда яшәр;

Бондюгым — гомер бишегем,
Син безгә газиз шәһәр.
Кушымта.

ЯШЬЛЕК ТОРА ТАШЫП

Яз кошлары күктә,
Яшьләр язны көтә,
Кояш нуры көләч йөзләрдә.
Яшьлек тора ташып,
Моң агыла шашып,
Сөю хисе кунган күзләргә.

Яшьлек яшьлек инде,—
Гүя алып килде
Сөю тулы назлы язларны.
Су буенда парлар,
Учак ягып алар,
Каршылыйлар киек казларны.

Язлар белән бергә
Кыр казлары килә,
Тик нигә бар ялгыз ак казлар?
...Шаулы язлар үтәр,
Сизми калыр күпләр,
Әйтерсең лә яшьлек шул язлар

КҮҢЕЛЕМ САНДЫГЫН АКТАРАМ

Буранда адашкан юлчыдай,
Адаштым уйларым эчендә.
Көзләрнең, аерылу кичендә.
Сөйләгән сүзләрен исемдә.

Сөйләгән сүзләрең күңелгә
Сап-сары яфрактай коелды,
Һәр сүзең, карашың, уйларың
Кургашын болыттай тоелды.

Болытлар җил чыкса тарала.
Таралмый һич кенә сүзләрең...
Юксынып, өздереп карыйлар
Бүген дә сагышлы күзләрең...

...Буранда адашкан юлчыдай,
Адаштым уйларым эчендә.
Күңелем сандыгын актарам

Кышларның буранлы кичендә...

МИНЕМ ХАЛКЫМ ИНДЕ УЯНДЫ

Очың очка ялгап күп яшәдек,
Бай булмадык гомер-гомергә.
Кара чырай күрсәтмәдек. Эчтән
Әйләнсәк тә кара күмергә.

Һәрчак булдык дуслар белән бергә,
Күңелләрне юктан күтәрдек.
Кайгысын да, шатлыгын да күрдек —
Авырсынмый бүлеп үткәрдек.

Заманалар кыен иде ул чак,
Юлдаш булды анам догасы.
Шул догалар ярдәм иткәннәрдер —
Ансыз тормыш авыр буласы.

Заманалар хәзер әллә җиңел?
Тормыш итү, ай-һай, кыен ла.
Ил болганып бетте. Сугыш бара —
Күпме җаннар юкка кыела.

Көчле рухлы булыйк. Киләчәктә
Заманалар, бәлки, үзгәрер.
Шундый өмет белән өметләнеп,
Яшәрләргә язган безгәдер.

Өмет бер хәл. Яхшы тормыш өчен
Көрәшмәсәк, кемнәр көрәшер.
Килер бер көн, әйтер халкым сүзен,
Безнең көрәш — изге көрәштер.

Очын-очка ялгап күпме яшик,
Эшчән халык шуңа түзәрме?
Халык аңлый, ул көрәштә бүген —
Гади халык бик тә үзгәрде.

“Волга”ларда кемдер элдерткәндә
Илем халкы яши талонга...
Күнел әрни, ярдәм итә алмыйм —
Халкым минем һаман талана.

Очын-очка ялгап яши халкым,
Беркайчан да ул бай булмады

Килер бер көн, әйтер халкым сүзен —
Минем халкым инде уянды...

Әйтмә миңа китәм инде, диеп,
Эндәшмичә китсәң ни була...
Әнә инде урамнарда буран,
Эзләреңә салкын кар тула.

Әйтмә миңа ялгыз каласың, дип,
Минем белән кала уйларым...
...Уйлар, уйлар инде. Чәчләремнән
Иркәләми йомшак кулларың.

Җилләр йөри сагышларны барлап,
Сагыш ята синең эзләрдә.
Әйтмә миңа ялгыз каласың, дип,
Өмет балкый әле күзләрдә.

Әйтмә миңа китәм инде, диеп,
Эндәшмичә китсәң ни була...
Әнә инде урамнарда буран,
Эзләреңә салкын кар тула.

Әйтмә миңа ялгыз каласың, дип,
Минем белән кала уйларым...
...Уйлар, уйлар инде. Чәчләремнән
Иркәләми йомшак кулларың.

Җилләр йөри сагышларны барлап,
Сагыш ята синең эзләрдә.
Әйтмә миңа ялгыз каласың, дип,
Өмет балкый әле күзләрдә.

ӘЙТМӘ МИҢА
Әйтмә миңа китәм инде, диеп,
Эндәшмичә китсәң ни була...
Әнә инде урамнарда буран,
Эзләреңә салкын кар тула.

Әйтмә миңа ялгыз каласың, дип,
Минем белән кала уйларым...
...Уйлар, уйлар инде. Чәчләремнән
Иркәләми йомшак кулларың.

Җилләр йөри сагышларны барлап,

Сагыш ята синең эзләрдә.
Әйтмә миңа ялгыз каласың, дип,
Өмет балкый әле күзләрдә.

АГЫЛА МОҢ

Агыла моң чишмә җыры сыман,
Агыла да нәфис, назлы моң.
Тын да алмый әсәрләнеп тыңлыйм,
Нинди көчләр, әйтче, монда соң?

Агыла моң. Камыш, курайларда
Әллә инде җилләр уйныймы?!
Әллә инде шушы иркен җиһан
Барлык моңны бергә җыйганмы?!
Агыла моң. Кичке эңгер аны
Еракларга илтә, еракка.
Нинди моң ул – бигрәкләр дә якын,
Шул кадәрле якын йөрәккә.

Агыла моң. Эзләп киттем аны:
Басуларга чыктым, кырларга.
Күңелкәем нык сусаган икән
Арышларым язган җырларга.

Таптым. Моңнар ярсып чыга икән
Игенченед йөрәк түреннән.
Отам җырны, онытмаска ятлыйм
Җырлар өчен аны күңелдән.

Агыла моң иртән дә кичен дә,
Галәм йөзә дәртле моңнарда.
Без яшәрбез әле бу дөньяда
Игенче һәм җирдә моң барда.

II. АККОШ МОҢЫ

ЯЗМЫШЛАРЫМ — ИГЕН КЫРЛАРЫ

Җир астыннан, кайнар мәхәббәттәй,
Салкын чишмә чыга ургылып,
Туган җирем, синдә гомер буе
Яшәдем мин тугры ул булып.

Шул чишмәнең саф суларын эчтем.
Ятак булды талның төпләре.,.

Кошлар җырын тыңлап таң аттырдым
Сихерләде айлы төннәре.

Тургайларым булды көй язучы,
Чылтыр чишмә — җырчы кызларым
Яшел җәйләү — бәллүр сиртмә иде.
Язмышларым — иген кырларым.

Шуңадырмы, иркен сулап яшим,
Ару белми эшлим кырларда.
Күңелемә тулган моңнарымны
Җырлыйм менә шушы юлларда.

КҮҢЕЛЕМ
Күңелкәем боеграк бүген,
Әнкәемне өзелеп сагынам.
Туган яктан бер әйләнер өчен
Очар коштай канат кагынам.

Күңелемдә бер дәрт йөри бүген —
Әткәемне күрдем төшемдә.
Ул йөрегән сукмаклардан йөрдем
Аяз төннең айлы кичендә.

Күңелкәем бер җилпенеп куя —
Яшьлегемне эзлим күптәннән.
Киләчәктә көтеп тора кебек,
Ә мин эзлим аны үткәннән.

Күңелемдә ниләр барын беләм,
Күңелемне һәрчак җыр баса.
Бар теләгем кабул була кебек,
Башакларым кырда җырласа.

МИЗГЕЛЛӘР
Таяныргa беркемем юк,
Йөрим карлы урамда.
Бер эшем юк җилләрендә,
Бер эшем юк буранда.

Дус-ишләр дә үткән була,
Таныш-белеш кул бирә.
Эч серем ачмыйм беркемгә,
Кул биргәнгә кул бирәм.

Уйлар берсен-берсе куа,
Күз алдымда дус-ишләр,
Авыр чакта таралалар —
Тараталар имешләр...

Таянырга беркемем юк,
Салкын үтә җаныма.
...Аякларым алып кайткан
Карт әнкәем янына...

ИСКӘ ТӨШӘ

Балачагым бик еш искә төшә,
Нинди керсез иде йөрәкләр!
Уй-хисләр дә шундый охшаш иде,
Тәңгәл килә иде теләкләр.

- Ашарыңа, дустым, бармы бүген?
-Бетеп китте әле умачым...
Зур бер касә арыш оны тотып,
Җәеп керде күршем колачын...

Еллар уза, уза гомерләр дә —
Бер-беребезнең хәлен белешми.
Йөрәгеңдә кайгың бар бугай, дип,
Күнел яктыларын бүлешми.

Бергәләшеп элек сука тарттык.
Уртак бүлдек бер уч юаны.
Кайберәүләр, һай, көченнән килсә,
Сатар иде сулар һаваны.

Бүлешми ул артык сыныгын да,
Койма биек ике арада.
Иңде кеше, кодрәтеннән килсә,
Акча сорар яуган карга да.

Якты көнне нечкә кыллап бүлеп,
Базарларга илтер сатарга,
Байлык өчен хәзер кайберәүләр
Туганын да әзер атарга...

...Нигә диеп сөйләп торам әле —
Бу дөньяда барын күрәсең...
Магазинда сантиметр белән

Тастымалга чүпрәк бүләсең...

- Ашарыңа, дустым, бармы бүген?
-Бетеп китте әле умачым...
Элек шулай иде:
Төенчеккә бодай оны төйнәп,
Җәеп керде күршем колачын!
Ә хәзер...

ЯШЬЛЕГЕМӘ КИЛЕП КЕРДЕҢ
Исеңдәме язлар килгән мизгел —
Чишмә кебек чылтырап көлдең син.
Сөюләрең белән назлый-назлый
Яшьлегемә килеп кердең син.
Шул язларда мәңгелеккә мине
Сөю утларына салдың син.
Чал керсә дә, унҗидедәгедәй,
Йөрәгемдә гүзәл калдың син.

Исеңдәме, язлар китә иде? —
Син китмәдең, миңа килдең син.
Алсу таңда чыклар яра-яра
Язмышыма килеп кердең син.

ӨЗЕЛЕП КӨТӘМ
Бергә булгап тымызык айлы кичләр
Чыкмас инде алар исемнән.
Сиңа атап моңлы бер җыр язсам,
Сөю хисләремнән исерәм.

Бергә йөргән яшел сукмаклардан
Сине эзләп күпме йөрмәдем.
Юксынам мин сине, очрашуны
Өзелеп көтә кайнар йөрәгем.

Бергә булган изге минутларны
Юк, онталмам, аңла, гүзәлем.
Синең белән булсам, тәмугның да
Бөтен газабына түзәрмен.

АҢЛАМАДЫҢ ЙӨРӘК ТИБЕШЕН
Сөям сине, сөям,
Газапланам.
Сизәсеңдер йөрәк тибешен,
Көн дә чыгам каршына мин—

Күз алдымда атлап килешең.

Өздереп лә басып килүләрең
Саный кебек йөрәк тибешен.
Уйларымнан чыкмый,
Онытa алмыйм
Гел елмаеп атлап килешең.

Сөйдем сине, сөйдем,
Газапландым.
Сизмәдең шул йөрәк тибешен.
Уйларымда,
Бары уйларымда
Уйнап-көлеп миңа килешең.

АРАННАРДА АТЛАР КЕШНИЛӘР
Әллә ничек күңелем бик җилкенә...
Араннарда атлар кешниләр.
Ул чакта бит атлардан да алда
Яуга киткән нде кешеләр.

Киттеләр дә күпләр кайталмады,
Башын салды яуда кешеләр.
Шул батырлар искә төште менә —
Араннарда атлар кешниләр.

Араннарда атлар берән-сәрән,
Заманасы аның башкарак.
Бик күп эшне саллы тимер көчләр
Һәм атомнар хәзер башкара.

Без белгән яу, белмәгәне күпме,
Юкса, җирдә тыныч чак тора.
Элеккеләр читтә, хәзергеләр
Цинк табутларда кайттылар.

Яна язлар җиткән саен шулай
Араннарда атлар кешниләр.
Искә төшә, җир селкетеп йөреп,
Юкка чыккай имән кешеләр.

Араннарда атлар кешниләр дә,
Күңелкәем ярсып җилкенә.
Иксез-чиксез утлар баса мине,
Гаҗизлектән җаным тилпенә.

ХАЛИДӘ
Карлар явып китте,
Кышлар инде җитте —
Кыр казлары очты күлләрдән.
Йөрмә янып -көеп,
Гөлләр сулды диеп,
Язлар яме янсын күзләрдә.

Кышлар үтеп бара,
Кар сулары ага —
Җанга рәхәт буген күңелгә.
Гөлләр чәчәк ата,
Киткән кошлар кайта —
Яшеллеккә дөнья күмелгән.
Тургайларга тиң син,
Язлар белән кил син.
Сандугачтай сайра моңланып.
Моңнар диңгезендә
Йөз әле бүген дә —
Җырлар белән күмеп дөньяны.

БАСУЛАРГА ЧЫК ТА
Басуларда тургайларны тыңла,
Тыңла әле ужым җырлавын.
Кар-юрганын инде салып аткан
Хәтфә-яшел арыш кырлары.

Басуларда күкрәк тутырып сула —
Язлар килә безнең төбәккә.
Сандугачлар җырын отып алдым,
Кәккүкләрнең моңы йөрәктә.

Кырлар дәшә безне, үзенә дәшә,
Нинди гүзәл язлар килгәндә.
Кайткан сыман булам яшьлегемә
Серле итеп кызлар көлгәндә.

Кызлар көлсә, кояш нурларында
Коенгандай басу-кырларым.
Басуларга чык та, тыңла, иркәм,
Сиңа атап язган җырларым...

СИН КИЛӘ КҮР
Юлларымда кинәт арып калсам,

Тотсаң, иркәм, минем кулымнан,
Шул чакларда сөеп бер карасаң —
Мин китәрмен тагын юлымнан.

Юлларымда кинәт арып калсам,
Килерсеңме минем каршыма?
Сөям, дисәң, очам кошлар булып,
Кочагыңны җәеп каршыла.

Югарымда арып калсам әгәр,
Син килмәсәң минем яныма,
Калыр бары җирдә нәүмизләнеп,
Ак күбәләк булып җан гына.

…Җирдә яшәү безнең кирәк әле,
Син килә күр берүк яныма.

ТУГАН АВЫЛЫМ — БӘЗӘКӘМ

Басуларда — башак җыры,
Тургай моңы кырыңда.
Зифа буйлы сылуларың
Уйный йөрәк кылында.

Кушымта:
Әй Бәзәкәм, Бәзәкәм,
Языңны көтеп алам.
Тирәк, камыш, каен моңын
Йөрәк җылыма салам.

Комбайннар, тракторлар,
Егетләр җырлый кырда.
Бер симфония язарсың,
Иренми тыңлап тор да.

Кушымта:
Әй Бәзәкәм, Бәзэкәм,
Языңны көтеп алам.
Тирәк, камыш, каен моңын
Йөрәк җылыма салам.

Иген игә егет-кызың,
“Кара алтын” таба илгә.
Шатланам, Бәзәкәм, мин бит
Синдә дөньяга килгән,

К у ш ымта:
Әй Бәзәкәм, Бәзәкәм,
Языңны көтеп алам.
Тирәк, камыш, каен моңын
Йөрәк җылыма салам.

КҮРЕП ТОРАМ ТАУ БАШЫННАН

Тау башыннан күреп торам,
Тирә-як уч төбендә.
Барча җиһан ак гөлләрдә,
Зәп-зәңгәрдән күгем дә.

Яшәреп чыккан чирәмдә
Йомшак чебиләр жимли.
Яз көннәре нинди ямьле —
Күзем аласым килми.

Йөгереп килә каен кызы —
Чәчләре тузгый җилдә.
Ал кояш озата бара
Тәгәрәп аны җирдән.

Җилбәзәк җилләр иркәли
Хәтфә чирәмне җирдә.
Бу җиһанның хозурлыгын
Син үзең кара кил дә.

СӨЮЕМ ЧАКЫРА

Юлаучылар озын сәфәр чыккан —
Гел чиге юк сыман юлларның.
Шулар кебек озын сәфәр кылам
Саный-саный гомер елларын.

Озын-озак барасылар бар бит —
Гыйшкым көтә безне еракта.
Сиңа булган мәхәббәтем һаман
Саклап йөртәм кайнар йөрәктә.

Көт син мине, алып килермен мин
Озын юллар аша сөюне.
Безнең гомерләргә дәрт өстәгән
Мәхәббәттә яныш-көюне.

Юлаучылар озын сәфәр чыккан,
Мин дә чыктым ерак юлларга.

Минем белән генә булсаң бары,
Үкенмәмем үткән елларга.

ГОМЕР, ГОМЕР...

Сылу кызлар озата барамыни —
Яшь каеннар кала тезелеп.
Әллә нигә, яшьлек искә төшкәч,
Үзәкләрем китә өзелеп.

Каеннар да олыгайган сыман —
Ябалдашлар җиргә сарыла.
Җәй булса да, белмим, әллә нигә
Яфраклары чумган сарыга.

Каенкайлар, нәрсә булды сезгә?
Алдыгызда сезнең яткан бар.
Ниләр курэм — суын эчәр өчен
Кәүсәгезгә балта чапканнар.
Гомерләргә балта чапканнар...

ТЫҢЛА ӘЛЕ

Тыңла эле: бер моң ишетелә,
Ул моңнарым чыга йөрәктәй.
Шул моңнарым язмышларны жиңеп
Яшәргә бит безне өйрәткән.

Тыңла әле, бер моң ишетелә —
Таныш алар күптән, күптәнге.
Сине көтәм таныш моңнар аша,
Якын итә алмыйм бүтәнне.

Тыңла әле, таныш моңнар ага
Талгын аккан сулар шикелле.
Гомерем буе көтәм,
Аңларсың дип, иркәм,
Башкаларны сөюем икеле.

Тыңла әле, бер моң ишетелә,
Бу моң әллә минем сагышмы?
Сөюемне кире каккан өчен
Сиңа диеп әйткән каргышмы?

ӘЙ КЕШЕЛӘР!..

Нишләдек без?
Каты бәгырьләндек,

Тупасланды хәтта йөзебез.
Нишләдек без? –
Алмагачлар кисеп,
Урынына гараж төзибез.
Ач-ялангач йөргән чаклар булды,
Әмма түздек,
Намус жуймадык,
Өстебездә бер кат кием булса,
Сандык шыплап байлык җыймадык.
Нишләдек без,
Алтын-көмешләргә
Алыштырдык бугай дуслыкны,
Озак еллар буе яшәп килгән
Гадәтләрме жую — дуслыкмы?
Кая китте безнең елмаюлар,
Кая китте безнең шатлыклар?
Кая китте безнең моңнарыбыз?
Һәр кешедә, юкса, шатлык бар.
Кая дуслык, кая туганлашу?
Сүнеп бара йөзебез нурлары.
Гранит кебек катты,
Заман белән килгән йогышлы чир
Күңелнең дә нурын урлады.
Әй кешеләр, сезгә эндәшүем:
Ташка әйләнмәсен күңелләр.
Җанварлар да берсен-берсе сөя —
Без элегә җанвар түгелләр.
Нишләдек без? —
Иманыбыз качты,
Гел алласыз түгел идек без.
Нишлибез без?
Гөлбакчалар чабып,
Урынына гараж төзибез...

СИҢА, ИРКӘМ

Нинди шатлык җирдә синең булу,
Нинди бәхет синең яшәвең.
Сөенәм мин — юлдаш булдың миңа,
Бәгырем, дип, сиңа дәшәмен.

Кайгыларны бергә-бергә җиңеп,
Ләззәтләндек тормыш көенә.
Бар булганым, җаным-тәнем белән
Шөкер итеп шуңа сөенәм.

Якын дустым булдың миңа һәрчак,
Тормышымда булдың юлдашым.
Син бул бары минем белән генә,
Сөю гөле генә сулмасын...

КҮҢЕЛЛӘРДӘ КҮКРӘҮ БУЛСА

Яңгыр явып узды,
Бар табигать
Өр-яңа шәл япты диярсең.
Күңелләрдә күкрәү, давыл булса,
Гүя яңа күлмәк киярсең.
Яңгыр явып узды, һавалар саф,
Күкрәк тутырып сулыйм, их, рәхәт!
Яшьнәүләрен, күкрәүләрең өчен
Йа ходаем, сиңа мең рәхмәт.
Яңгыр явып узды,
Ул шифалы яңгыр —
Пар бөркелә хәтфә җирләрдән.
Бушанулар көтәм йөрәгемә
Янгыр, күкрәү, давыл, җилләрдән.

ЙӨРӘГЕМДӘ АВЫР ТАШ БАР

Йөрәгемә ташлар булып төшә —
Тал мамыгы ява җирләргә.
Гомеркәем ялгыз казлар сыман
Моңсу үтте чит-ят җирләрдә.

Йөрәгемә авыр ташлар булып,
Мамык карлар ява җирләргә,
Һәр иртәдә сагышларым барды
Тугай якка назлы җилләрдә.

Йөрәккәем җиңеләйде бугай —
Кире кайттым туган җирләргә.
Мәхәббәтем ядкарь булып яткан
Яшьлегебез йөргән җирләрдә
Назлап утте шифа җилләр дә...

ТАНЫШ МОҢНАР

Таныш моңнар — талгын сулармыни,
Салмак кына ага кичләрен.
Шундый кичтә бүләк иттем сиңа
Яшьлегемнең гүзәл хисләрен.

Хисләремне сиңа биргән өчен

Үкенмим гел, һич тә үкенмим.
Югалтулар,
Юксынулар аша
Шул моңнарны эзләп килдем мин.

Таныш моңнар — минем үткәннәрем,
Таныш моңнар — йөрәк сагышым.
Шул моңнарны күңелемнән көйләп,
Үткәннәргә кайтып барышым...
Киләчәккә үтеп барышым...

ҮПКӘЛӘМӘ МИҢА

Үпкәләмә әле, үпкәләмә,
Үпкәләргә, беләм, хаклысың.
Бергә булган матур мизгелләрне
Ядкарь итеп күптән саклыйсың.

Үпкәләмә, мин дә газапланам:
Сөешсәк тә, кавышып булмады.
Әче итеп бездән язмыш көлеп,
Аерды шул гомер юлларын.

Үпкәләмә, мин дэ өзгәләнәм.
Кайтарып ла булмый үткәнне.
Куш тирәк төбендә, хәтерлимсең,
Тәүге тапкыр сине үпкәнне.

Үпкәләмә инде, сыкранам мин,
Истәлеккә калды үткәннәр.
Ирен очларында ялкын булып
Һаман тора суырып үпкәннәр.

Үпкәләмә, өзлеп сөюләрнең
Аңладым мин кирәк түгелен.
Тик ни эшлим,
Тик син генә белмә —
Мәңге көтәр сине күңелем...

...Үпкәләмә, үпкәләмә миңа.
Үткәннәрне булмый кайтарып...
Бүген тагын сине табып алдым
Күңел хәзинәсен актарып.

МИНЕМ ТЕЛӘГЕМ
Болыннарга кара,
Тургайларны барла—
Яшел хәтфә бөтен дөньясы.
Нидер көтәм сыман, йөрәгем ярсыган —
Яз көннәре, иркәм, шундый чак.

Урманнарга кер син,
Гүзәллекне күр син —
Моң-назларга күңел ашкына.
Йөрәк нидер даулый,
Күкрәкләрне айкый
Ярсып аккан дәрья-ташкындай.

Зәңгәр күккә карыйм,
Тургай җырын аңлыйм,
Кошлар җыры — йөрәк моңсына.
Сагыш кирәк түгел,
Яздай булсын күңел —
Теләкләрем минем шул сиңа.

ЧИШМӘЛӘРГӘ БАРГАН ИДЕМ
Чишмәләргә барган идем,
Чиләкләремне асып.
Мәхәббәт килде каршыма,
Тар сукмакларга басып.

Чишмәләргә барган идем,
Гел белеп бардым микән.
Сукмакларда каршы алдың
Син мине иртән, иркәм.

Ярый барганмын чишмәгә —
Мин нишләр идем синсез.
Җиде баланың әтисе
Булалмас идең минсез.
...Сылу кызым усеп җитте,
Чишмәгә суга китте...

ӘНКӘЙ, САУМЫ?
Әнкәй, саумы?
Минем кайтуымны
Көтәсеңдер һәр көн сагынып.
Язлар җитсен инде,
Җирләр кипсең инде,

Кайтырмын мин коштай кагынып.

Һәр минутым, һәр сәгатем минем
Сине генә уйлап үтәдер.
Көт син мине, әнкәй,
Көт син мине, бәгърем,
Үкенмә лә гомер үтә, дип .

Изге орлык - без бит балаларың,
Тугай илгә хезмәт итәбез.
Синең белән булу мизгелләрен
Айлар аша өзелеп көтәбез.

Без кайтырбыз,
Әнкәй , тик көт кенә,
Син бит безнең өчен бер генә...
...Еллар үтәр, менә бүгенгедәй
Сакланырсың безнең күңелдә.

КАЕН
Иңнәренә кәшмир шәлен япкан,
Гөл-чәчәкләр аның төбендә.
Каен кызлар әйлән-бәйлән уйный,
Кошлар җырлый зәңгәр күгендә.

Юл чатында баскан да ул шулай,
Һәр ел саен язны каршылый.
Дулкынлана җилдә ябалдашы,
Гәүдәсендә хәсрәт ташкыны.

Киткән чакта ирләр чит илләргә,
Утыртканнар шушы каенны...
Еллар узгач, бик азлары килеп
Уртаклаша сагыш-кайгыны.

ТУГАН ТУФРАК, ТУГАН НИГЕЗ
Сагынып кайттым кырларыңны,
Салкын чишмә суларыңны,
Яшьли сөйгән кызларыңны,
Моңлы, салмак җырларыңны.

Әйе, кайттым әле сиңа,
Үпкәләмә инде миңа.
Гафу үтенәмен шуңа,—

Туган туфрак, туган нигез.

Зәңгәр күктә дәртле тургай
Мине каршы ала шулай.
Сине өзелеп сагынганга
Күңелкәем дулый, шаулый.

Кабул итеп алчы мине,
Үзеңнән җибәрмә инде.
Беркайчан калдырмам сине,
Туган туфрак, туган нигез.

Иртән искән җилләреңне,
Бәхет ташкан җирләреңне
Йөрәгемдә саклап йөрттем,
Кавышуларны өзелеп көттем.

Озак йөрдем еракларда,
Зур йөк бирде йөрәкләр дә.
Сиңа кайттым: без бит— игез,
Туган туфрак, туган нигез.

МИН БӘХЕТЛЕ БҮГЕН

Ялгышмыйча мин көткәнмен икән
Сөюләрнең соңлап килгәнен.
Елмаюың төшләремә керә,
Төшләремдә синең көлгәнең.

Ялгышмыйча мин көткәнмен икән —
Миңа кабат яшьлек юлладың,
Нинди озын булды, белсәң икән,
Сиңа илткән язмыш юлларын.

Ялгышмыйча мин көткәнмен икән
Иркәләвең алсу таңнарда,
Мин бәхетле бүген, соң булса да
Яннарымда, иркәм, син барда.

ИРКӘМӘ

Таңнар ата,
Сызылып таңнар ата,—
Моң җәелә иркен кырларга,
Башакларның шавы килеп кушыла
Йөрәгемнән чыккан җырларга.
Таңнар ата,

Сызылып таңнар ата,
Бәхет булып туган җирләргә.
Иркәлән син, иркәм,
Назлап да син иртән
Талгын искән йомшак җилләрдә.
Таңнар ата,
Сызылып таңнар ата,—
Таң чакыра мине иркәмә.
Сиңа сагынып килдем,
Мин синеке инде,—
Кочагыңа алып иркәлә!..

СИНДӘ КАЛАМ

Шәһәр кысасында үтте язым
Тургай җырын тыңлый алмадым.
Басуларга чыгып, күкрәк тутырып,
Саф һавалар сулый алмадым.
Әллә бу ел яз да булмадымы?
Ничек килде язлар — сизмәдем.
Узып киткән чакта күреп алып,
Моңсу гына кулым изәдем.
Йөрәгемә авыл, басу кирәк,
Башакларның кирәк җырлавы.
Игенченең йөрәк моңы кырда —
Шул моңнардан дәртле җыр бармы?
Күңелкәем бәйгедәге аттай,
Киң кырларга тарта, җилкенә...
...Шәһәр асфальтларын айкап йөри
Моңсыз калган көзге җил генә.
Көзем үтте шәһәр кысасында,
Кыр казларын озата алмадым.
...Моңсу миңа кырларымнан башка —
Тагын бер кат шуны аңладым.

ИХ, ИРКӘМ, БЕЛМИСЕҢ

Күкрәгемдә утлар яна,
Их, иркәм, син белмисең.
Ялкыннарын басар өчен
Салкын су да бирмисен.
            Матурым син, гөлем син,
            Сине кайчан күрим соң?!
Тальян гармунымда уйнап,
Турыгыздан үтәмен.
Бергә булу минутларын
Өзелеп-өзелеп көтәмен.

Шатлыгым син, гүзәлем,
Синссз ничек түзәрмен?!
Тәрәз пәрдә читләреннән
Качып кына багасың.
Никләргә соң уттан алып,
Тагын утка саласың.
Сөям сине, сөям, бел,
Бергә булыйк, безгә кил.

ӘКРЕН ГЕНӘ ТАУГА МЕНӘМ

Үрләр аша үрли-үрли
Биек тауга менеп барыш.
Юлларымда сәлам бирә
Баш тутырган бодай-арыш.

Үрләр аша үрли-үрли
Тау менүләр, ай-һай, авыр.
Фатихасын бирде миңа
Туган туфрак, туган авыл.

Үрдән-үргә үрли-үрли
Алда торган тауга менәм,—
Тормыш тавын җиңә-җиңә
Дуслар белән, халкым белән...
Әкрен генә тауга менәм...

КӨЯНТӘҢНЕ САЛДЫМ ИҢЕМӘ

Чөеп бәйләп чиккән яулыгыңны,
Суга килдең зәңгәр чишмәгә.
Салкын сулар алдың,
Ромашкалы
Чиләгеңне асып сиртмәгә.
Кайтыр сукмакларда каршы алдым —
Көянтәңне салдым иңемә.
Көянтәңне салдым,
Тынычлыгым алдың
Шул кичтән соң, кызый, син генә.
Чиләкләрдән сулар чайпалгандай,
Тулып ашты сөю хисләрем.
Көн дә шулай каршы алам сине
Чишмә юлларында кичләрен.
Җәйләр үтәр, салкын кыш та җитәр,
Сукмакларны басар кар-буран.
Сыйдырырмы?
Әй, сыйдырыр әле

Саф хисләрне безнең киң урам.

АККОШЛАРНЫҢ МОҢЫН АҢЛАСАҢ

Көзге күлдә аккош йөри йөзеп,
Ак мамыгы оча җилләрдә.
Нигә икән дусларыннан калган,
Киталмыйча салкын җирләрдә?

Ак карлары белән кыш та җитәр
Аккошкаем, ни хәл итәрсең?
Ниләр булды, әйтче, яшермичә,
Җылы якка ничек китәрсен?

-Туган якта торып калам инде,
Кемнәр калыр, мин дә калмасам.
Син сорамас идең, Җир кешесе,
Аккошларның сагышын аңласаң...

ӘЛФИРӘ

Кышын гаҗәп инде, каеннарга
Ак мамыктан япкан өрфия.
Ямьле вакыт — салкын кыш уртасы
Беләсеңме шуны, Әлфирә.
Шул кышларга карап хозурланам —
Син ак кышны кырыс чак димә.
Ал кояш та шундый назлап көлә —
Күрәсеңме шуны, Әлфирә.

Киткән кошлар кире кайтыр әле,
Кышлар үтеп тагын яз җитсә.
Кайтыр кошлар кебек моңлы да син -
Беләсеңме үзең, Әлфирә.

ТУЛПАР АТЛАР ЧАБА

Атлар чаба, тулпар атлар чаба,
Ут-очкыннар оча тояктан.
Шул атларда сиңа илтер өчен
Сәлам язам туган яклардан.
Сәламнәрем, бәлки, барып җитәр
Бөдрә яллы тулпар атларда.
Шул атларда сәламнәрең кайтыр
Сагындырып, туган якларга.
Тулпар атлар канатланганмыни —
Очып бара сезнең якларга,
Сәлам нәрсә,
Сөюләрең белән
Син үзең кайт тулпар атларда.

ЯЗЛАРНЫ КӨТӘ КҮҢЕЛ

Язларны көтә күңелем
Әллә нигә ашкынып.
Давыл көткән бөркетмени —
Көтә язның ташкынын.

Язларны көтә күңелем,
Тик арада кышлар бар.
Алмагач чәчәкләредәй
Ява әнә ап-ак кар.

Язларны көтә күңелем.
 Көтмидер идем элек.
Язын карлыгачлар белән
Син дә кайтырсың кебек.

Язларны көтә күңелем,
Юксынам сине, иркәм.
Сине уйлау җиңел түгел,
Шулай да рәхәт икән.

ЯЗЛАР БЕЛӘН КИТӘРМЕН

(Җыр)

Кышлар китәр әле,
Язлар җитәр әле.
Карлар эрер кояш назына.
 Кайтыр карлыгачлар,
Сайрар сандугачлар,
Без керербез бәхет язына.

Язлар җитте инде,
Җирләр кипте инде,
Баш калкыта хәтфә үләннәр.
 Күктә тургай җырлый,
Тургай моңын тыңлый
Басу-кырлар, болын-үзәннәр.

Язлар белән килде,
Мәхәббәтем изге —
Сиңа сөю бүләк итәмен.
Кабул итмим, дисәң,
Сөюемнән көлсәң —
Язлардан мин җәйгә китәрмен.

КАЙТА ИКӘН, КАЙТА ҮЛГӘННӘР

Үлгәннәрне кире кайтмый, диләр,
Кайта алар,
Кайта үлгәннәр.
Иле өчен яуда калганнарның
Кайтып килгәннәрен күргән бар.

Күргәнем бар: кара кәгазь булып,
Кайтты алар теге елларда.
Күргәнем бар: орден, медаль булып
Озак йөргәннәрен юлларда.

Күргәнем бар: изге Җир өстендә
Һәйкәл булып тора һәркайда.
Үлгәннәрнең йөрәкләре тибә
Мәңгелек ут булып мәйданда.

ТУГАН ҖИРНЕҢ КИТМӘС КОШЛАРЫ БЕЗ

Илгиз Закиров музыкасы

Чәчәкле җәй үтте,
Моңсу көзләр җитте —
Очар кошлар китте тезелеп,
Һаваларда очкан,
Зәңгәр күкне кочкан
Кошлар кебек идек без элек.

Очар кошлар очсын,
Зәңгәр күкне кочсын —
Ә без калыйк туган төбәктә.
Туган җирнең яме —
Яшәешнең тәме.
Тамыр җәйган безнең йөрәктә.

Яшел язлар җирдә,
Сагыну моңы җилдә —
Киткән кошлар кайта ашкынып.
Гел яшисе килә,
Бер яшьнисе килә —
Җанга тула бәхет ташкыны.

Язгы күкрәү кебек,

Яздай карыйк көлеп —
Эреп аксын салкын кышлары.
Без — җилкенеп очкан,
Зәңгәр күкне кочкан,
Туган җирнең китмәс кошлары,
Яз ясаучы китмәс кошлары.

КӨТ ӘЛЕ, ДИСЕҢ

(Җыр)

Аңлый алмыйм мин,
Аңлый алмыйм мин:
Әллә сөясен, әллә сөймисен.
Уза гомерләр,
Уза гомерләр,
Көт әле дисен, көт әле. дисең.

Чәчләр агарган,
Чәчләр чаларган,
Әллә шаяртып, уйнап йөрисең.
Сөю утында
Яндырасың да
Көт әле, дисең, көт әле, дисең.

Яшьлекнең таңын
Бергә каршылап,
Күпме соң әле ялгыз йөрисем?
Чәчәкле язлар,
Күнелдә назлар.
Көт әле, дисен, көт әле, дисен.

Көттереп килгән
Сөю — гомерле,
Җанымда минем, иркәм, бары син.
Мәңге көтәргә риза булсам да
Көт әле, дисең, көт әле, дисең.

ТИРӘКЛӘРЕМ

Инеш буенда тирәкләр
Моңланып уйга талган.
Яшел читле сукмакларда
Яшьлекнең эзе калган.

Шул эзләр мине һаман да
Чакырып, әйдәп тора.

Яшьлек ул мәңге үзгәрмәс
Чәчәкле җәйдә тора...

Тирәкләре дә яшьлекнең
Гел уңмый, яшел төсле.
Шаян яшьлек, кыңгырауда
Челтерәп дәшәр төсле.

Кайттым.
Инде сукмакларны
Үләннәр баскан икән,
Тирәкләр кебек иелгән,—
Ул сезнең башлар икән.

Тирәкләр танымый бугай,
Ятсынып карап тора.
Көмештәй якты сулар да,
Нигәдер, кара тора...

Озак йөрелде бугай шул,
Озак йөрелде бугай.
Туган якның хәтереннән
Чыгадыр кеше шулай.

Аңладым соңлап:
Мин монда
Шаулыйсы тирәк икән.
Бу җирдә тамыр җәяргә,
Яшьлегемнең тирәкләре,
Сез миңа кирәк икән!..

СОҢЛАГАН ЯЗЛАРДАЙ

Соклаган язлардан килдең дә.
Йөрәкне хисләргә чорнадың.
Унҗиде яшемә кайттым мин,
Эзләре калса да чорларның.

Соңлаган язлардан килдең дә,
Иркәләп, моңнарда назладың.
Тургайлы таңнары кайткандай,
Бергәләп уздырган язларның.

Соклаган язлардай килдең дә,
Канатлар үстердек, мәхәббәт.
Үзгәрттең язмышны, үзгәрттең,

Мең рәхмәт, мәхәббәт, мең рәхмәт!

ӘНИСӘ

Илгиз Закиров музыкасы

Зәңгәр күктә ярсып тургай җырлый,
Талгын гына язгы җил исә.
Язлар кебек матур, гүзәл дә син
Сөенечкә минем, Әнисә.

Сары шәлен ябына ак каеннар,
Гөлләр шиңә алтын көз җитсә.
Йөрәгемдә дөрләп сөю яна,
Сизәсеңме шуны, Әнисә.

Очып кайтыр идем. язмыш миңа
Яшьлегеңә кире кайт, дисә.
Тормыш юлын бергә узарга гомергә
Сайлар идем сине, Әнисә.

ЯЗЛАРДАН АЛАЛМЫЙМ КҮЗЕМНЕ

Луиза Батыр-Болгари музыкасы

Бәхеткә төренгән,
Шатлыкка күмелгән
Беренче ярату язлары.
Сагынып язларны,
Эзләп бу якларны,
Тезелеп кайта кыр казлары.

Бар җиһан яшәрә.
Дәрт ташый яшьләрдән,
Һәркемгә яз сөю өләшә.
Яр таба ярларны,
Яз сыный аларны,
Парлардан хәтта Ай көнләшә.

Көнләшмә, тулган Ай,
Яныңда Зөһрә бар,
Бәхетле сана син үзеңне.
Сөюгә күмелгән,
Шатлыкка төренгән
Язлардан алалмыйм күземне.

ГӨЛЗИРӘК

Һәр язда бакчамда пар шомырт
Болыттай чәчәккә төренә.
Елмаеп, уйланып, моңаеп,
Калдык син күңелем түрендә.

Үткәнгә кабаттан әйләнеп
Кайтырга ашкынам яңадай.
Әле да сулкылдый йөрәгем
Яшьлектә калдырган ярадан.

Бернинди дарулар төзәтми —
Аңа бит бары тик син кирәк.
Кайтыр дип өзелеп көтәмен,
Кайт инде, күз нурым, Гөлзирәк.

БАЛАЧАК РӘСЕМЕ

Сания Узлова музыкасы

Ясап кундым ап-ак кәгазьгә мин
Ал кояшны алсу буяу белән.
И, әбием бер сөенсен әле —
Рәсемемне бүлмәсенә эләм.
Сөйгән әбиемнең бүлмәсенә
Көлтә-көлтә нурлар тулсын әле.
Шул нурларга карап, әбиемнең
Сөенечтән күңеле булсын әле.

Мин кояшны ясыйм бик күп итеп,
Әтиемә, әниемә бирәм.
Кояш нурларына чумсын, әйдә,
Бөтен авыл, бөтен күрше-тирә.

Кояшлар күп булсын, әйдә, җирдә,
Кояш нурларына тулсын илем.
Ал буявым, ап-ак кәгазьләрем
Һич бетәрлек түгел әле минем...

КИЛМИСЕҢ СИН КӨЛЕП

Зөфәр Хәйретдинов музыкасы

Таңнарда уянам,
Таңнарда уйланам—
Мнн сине һаман да юксынам.
Көннәрем төн кебек,
Килмисең син көлеп —
Дөньяда яшәвем юк сыман...

Ә йөрәк сагына,
Уй канат кагына —
Җилпенеп очам мин янына.
Күңелдә көз кебек,
Килмисен син көлеп —
Сагыш-моң коела җаныма...

Юлларны күзлим мин,
Гел сине эзлим мин-—
Нур тулы күзләргә яшь тула.
Кояшлы чык кебек,
Килмисең син көлеп —
Бер генә килсәң сон, ни була?!

АНА
Юл читендә басып тора ана,
Күкрәгенә куеп кулларын.
Гүя шулай озата бара һаман
Яуга киткән газиз улларын.

Юл читендә басып тора ана,
Күкрәгенә куеп кулларын.
Гүя шулай сорый ходайдан ул
Исән кайтсын, диеп, уллары.

Юл читендә басып тора апа,
Күкрәгенә куйган кулларын.
Гүя шулай сагынып каршы ала
Җиңеп кайткан батыр улларын.

Юл читендә басып тора ана,
Күкрәгенә куйган кулларын.
Гүя шулай каршы ала һаман
Яуда калган үлмәс улларын.

ВӘГЪДӘ БИРИК
Нигә икән, иркәм,
Көн дә шулай иртән
Ярларыннан ургый хисләрем,
Һич тә тыныч түгел,
Сиңа тарта күнел —
Зарыгып көтәм килер кичләрем.

Язгы айлы кичтә

Йөзәбез без хистә —
Берсен-берсе назлый иреннәр.
Йөрәкләр еш тибә,
Бер генәм син, дия,—
Береккәннәр безнең күңелләр.

Бозлар ташып ага,
Яшьлек ишек кага,—
Икебез дә татлы хисләрдә.
Сине өзелеп сөям,
Сөям, янам-көям,—
Вәгъдә бирик язгы кичләрдә.

КЕШЕГӘ

Шигырь язу минем һөнәр түгел,
Әмма алам кулга каләмне.
Җаным-тәнем белән саклар өчен,
Кочып алам бөтен галәмне.

Һәм кычкырам барлык кешелеккә:
— Җир әйләнә минем кочакта,
Йөрәк кебек бер туктарга мөмкин
Ни эшләрсең, Кеше, шул чакта.

* * *

Кабаланып Вакыт үтеп бара,
Ә сизелми аның узганы.
Тик чәчләргә генә кунып кала
Елларының аксыл тузаны.

* * *

Тәмле ашый, тыныч йоклый кеше,
Рәхәт аңа яшәү дөньяда.
Тик бәхетле була шул чак кеше:
Сөйгән халкы, туган тел барда.

МӘРФУГА ТҮТӘЙ КИБӘНЕ

Болын келәм төсле.
Төрле-төрле
Күбәләкләр уйный гөлләрдә.
Талгын җилләр сәфәр кылып йөри,
Алтынсыман аяз көннәрдә.

Менә инде ике атна булыр
Юк яңгыры, юк бер болыты.
Печәнчеләр кызу эш өстендә,
Җырлар айкый бөтен болынны.

Чүмәләләр кибәннәрне ясый —
Мәрфугаттәй кибән өстендә.
Ак яулыгы — яшьлек елларыннан
Истәлеккә калган төс кенә.

Шул яулыгын ничә еллар инде
Чөеп бәйли печән өстендә.
Ак яулыктай керсез гомере аның —
Без яшьләргә тапсыз төс кенә.

...Егерме яшь. Ак яулыгын болгап,
Озатып калды ирен сугышка.
Кайтмады шул.
Көтте, әле дә көтә,
Көтәчәк ул соңгы сулышка.

Шәрифҗаны кибән куя иде,
Башкаенда иде түбәтәй.,.
Менә инде бүгенгәчә, дуслар,
Кибән куя безнең Мәрфугаттәй.

Түбәтәйдәй матур кибәннәре —
Мәрфугаттәй кибән өстендә.
Ак яулыгы — яшьлек елларыннан
Истәлеккә калган төс кенә.

СИНЕҢ ӨЧЕН
Синең өчен алсу таңнар ата,
Синең өчен исә җилләр дә.
Синең өчен сандугачлар сайрый,
Синең өчен чәчәк җирләрдә.

Синең өчен тук башаклар шаулый
Иксез-чиксез басу-кырларда.
Синең өчен яңа көннәр туа.
Синең өчен туа җырлар да.

Синең өчен салмак җилләр исә,
Синең эчен яшен яшьни, дим.
Синең өчен җиргә килүләрем,
Синең өчен генә яшим мин.

Тик беләкүр минем кадеремне —
Югалтма син мине, югалтма...

...Мин булганга шулай гүзәл дөнья,
Син булганга шулай таң ата.
Соң булса да кадеремне бел син,
Һич югалтма мине, югалтма...

ТӨШЛӘР, ТӨШЛӘР...

Кайберәүләр төштә күктә оча,
Колач җәеп, йөзә диңгездә.
Кайберәүләр өр-яңа йорт төзи
Ата-ана торган нигездә.

Кайберәүләр атка менеп чаба,
Кайберәүләр коча сөйгәнен.
Кайберәүләр әрни-әрни карый
Изге җирнең янып көйгәнен.

Кайсыберсе үлеп янә туа,
Кайберәүләр төштә яшәрә.
Кайберәүләр кулы белән тотып,
Яшенгә дә бирми яшьнәргә.

Кайберәүләр гел мәңгелек инде:
Атсалар да, имеш, үлмидер...
...Шунысы чын: кеше төшләрендә
Эшсез чагын бер дә күрмидер.

КӨТМӘ МИНЕ, ЯМЕ!

Сеңелем,
Сермә керфекләреңне син
Нигә инде шулай буядың?
Кичен күргән тушьлы күзләреңне
Төнлә белән куркып уяндым.

Сеңелем,
Битләреңдә кояш алсулыгы,
Буяма син аны, буяма.
Кершәнләнгәч чибәр булам, диеп,
Валлаһи, дип әйтәм, уйлама.

Сеңелем,
Алтын төсле озын толымнарың
Ниләргә сон зәңгәр итәсең?
Пәрдә читләреннән карап кына
Төннәр буе нигә көтәсең?

Сеңелем,
Көтәсең син мине, әйе, беләм —
Мин — кемнеңдер өзелеп сөйгәне.
Буянып та көтмә,
Буянмый да көтмә —
Беркайчан да көтмә килгәнне...

УЙЛАГАНЫҢ БАРМЫ?

Гомер кыска,
Әйтерсең лә тормыш
Кошлар кебек оча,
Калышмый.
Аккошлар да моңлы итеп җырлый
Җылы якка, очып барышлый.
Гомерләрдән иң-нң кыска ни бар?
Бармы шуны унлап бакканың?
Аккош җыры кебек моңлы булсын
Яшәгәнең,
Бала бакканың...

СИН МИНЕ БЕЛМИСЕҢ.

Син мине сыгылды, дисеңдер?
Йөридер, дисеңдер, җан атып.
Син мине белмисең,
Килдем мин
Бу җиргә сөелеп, яратып...
Сөйдем дә, сөелә белдем мин,
Ниләр бар — барсы да күңелдә,
Моңнарның төссезе йөрәктә,
Яктысы дөньяга түгелгән...
Баш имим борчуга, ышаныч
Ак нурлар иңдерә көемә.
Сөенәм дөньяга килгәнгә,
Дөньяда яшәүгә сөенәм...
Син мине сыгылды, дисеңдер,
Яшидер, дисеңдер, җан атып.
Син мине белмисең,
Килдем мин,
Бу җиргә сөелеп, яратып...

ГӨРЛӘВЕКЛӘР

Гөрләвекләр чаба урам буйлап,
Гөрләвекләр чаба уйнаклап.

Күтәрелә җирдән парлы җылы,
Әйтерсең лә кемдер ут яккан...
Күңелдә дә ут ягылган кебек,
Кабынырмын сыман гөлт итеп...
Зәңгәр күзле шаян сылу төсле
Серле итеп дәшә күк чите.
Күк күзенә карыйм сихерләнеп,
Бәхет тулы ерак-еракка...
Моң диңгезем эзләп ашкынамын,
Гөрләвекләр кебек уйнаклап...
Бар дөньяның борчу-мәшәкате
Онытылып тора беразга...
Яшәү дәрте тулы хисләр белән
Күңелләргә керә бу язлар...
Гөрләвекләр чаба урам буйлап,
Гөрләвекләр чаба уйнаклап...

ТУГАН ЯГЫМ

Юллар йөрү— олы шатлык миңа,
Дөнья күреп, илләр гизәм мин.
Туган яктан ераклашкан саен
Тарту көчен күбрәк сизәм мин.

Туган якның искән җилләре дә,
Камыш шаулавы да кадерле.
Синдә чакта гына, туган ягым,
Белмибез күк синең кадерне.

Юл йөрүдән, ил гизүдән кайткач,
Аунадым мин йомшак чирәмдә.
Сагыну канатында очып кайтам,
Китсәм әгәр ерак җирләргә...

Юллар йөрү — олы шатлык миңа
Мин дөньяны ничә әйләндем
Юл йөрүләр миңа шатлык булса,
Синдә яшәү — үзе бәйрәмдер...

ЧИКСЕЗ ХӨРМӘТЕМ

Кайтып киләм басу сукмагыннан,
Тук башаклар нидер серләшә.
Туган илнең иркен басулары
Һәр кешегә бәхет өләшә.

Тозлы тире тамган игенченең

Басуларга, шушы кырларга.
Бер җыр эзләп, күңел ашкына гел,
Башак шавы кушыла җырларга.

Башакларның назлы көйләренә
Гомер буе сүзләр эзләдем.
Игенчегә атап җырлар яздым.
Җырладым мин шуны, түзмәдем.

Зәңгәр күктә тургай тынган күптән,
Язлар җиткәч тагын җырлар ул.
Ятын җирне кочам —
Сездән башка
Яши алмам, иген кырларым.

Җир сулышын тоям иртә язда,
Яшәү көче бирә хезмәтем.
Җиргә тормыш,
Гомер бүләк иткән
Игенчегә — чиксез хөрмәтем.

ҖИРЕМӘ

Күккә мендем җирдән аерылып,
Диңгезләргә киттем ярлардан.
Сагышларым кире алып кайтты,
Мин бит шушы җирдә яралган.

Туфрагында,
Үләнендә аунап,
Чишмә суын эчеп үскәнмен.
Истән чыкмый Кармантау буенда
Дуслар белән маллар көткәнем.

Әрәмәдә гөләп, балан җыйдым,
Күрәннәрен чаптым сазлыкның.
Дусай күлләрендә дуслар белән
Алтыннарын сөздек балыкның.

Күл суында пешкән балыкларның
Их, тәмле дә була шулпасы...
Мәңгелеккә җиргә береккәнмен,
Ник омтылам җиргә шул чаклы?

Тарту көчең бардыр синең, бәлки,
Мин бит сиңа һаман тартылам.

Әгәр, җирем,
Барыр җирең булса,
Мин китәрмен синең артыңнан.

МИНЕМ ӨЧЕН АГА ЧИШМӘЛӘР...

Хәл белергә авылдашлар килә,
Хәл белергә килә дус-ишләр.
Сәлам биреп алсу таңнар ата
Челтер-челтер ага инешләр.

Исәнме, дип кочагына ала
Тугайларым, басу-кырларым.
Җилдә уйнап дулкынланган басу
Җырлый миңа сагыну җырларын.

Сагынамын. Ике ел буена
Күрми тордым тугай якларны.
Бик еракта, кояш чыккан якта
Туган илнең чиген сакладым.

Туган яктан килгән хатлар аша
Мин яшәдем сезгә табынып.
Сөю канатында очып кайттым
Сөйгән ярны өзелеп сагынып.

Җаннарга дәрт өсти гүзәл моңы
Газиз җирне сөю җырының.
Минем гомер — иркен басу-кырлар,
Мин — солдаты иген кырының.

...Хәл белергә килә авылдашлар,
Хәл белергә килә дус-ишләр.
Бүген бары минем өчен генә
Җырлый-җырлый ага инешләр.

ТИК КӨТӘБЕЗ КӨЗ АЕН

Таң йолдызым, дисәм дә мин,
Зәңгәр күктән үзгә мин.
Җирдә үскән роза гөлем,
Сине җирдән эзләдем.

Кашың — карлыгач канаты,
Күзләрең шомырт кара.
Көн дә очрашасы килә,
Ерак булса да ара.

Билкәйләрең зифа талдай,
Сүзләрең юкә балдай.
Бөтен тынычлыгым алып
Ник ерак киттең алай?

Якынайтып араларны,
Күрешәбез ай саен.
Кавышырга вәгъдәләр бар,
Тик көтәбез көз аен.

Туйга чакырам, дусларым,
Парлап туйга килегез.
Безнең адрес үзгәрмәде —
Элеккечә, белегез.

* * *

Табым булмый кибетендә, базарында,
Тигәнме әллә шул әйбергә берәр үләт.
Чык базарга, рәхәтләнеп сатып ята,
Кирәгеңне биш бәягә спекулянт.

ОНТЫЛМЫЙ ШУЛ

Исән генә кайтып җиттегезме,
Сагынып көткән киек казларым?..
Алтын көздә кызыл туйлар булды,
Бик күпләре китте кызларның.

Сезнең кебек китә тора кызлар
Көз җиткәндә,
Кышлар килгәндә.
Тик кайтмыйлар алар,
Казлар кебек,
Кышлар үтеп, язга кергәндә,

Онтылмый шул!
Тора күз алдында
Чиккән яулыклары җилфердәп:
Кыр казлары очып кайтамыни
Туган төбәкләргә яз эзләп!..

* * *

Бәхетлемен дип, син бер дә һаваланма —
Бәхет белән хәсрәт һәрчак йөри бергә.
Бәхетсезмен дип син бер дә хафаланма —
Өйрәтә ул бәхетнең кадерен белергә.

СОҢЛАГАН ЯЗЛАРДАЙ

(Җыр)

Соңлаган язлардай килдең дә,
Йөрәкне хисләргә чорнадың.
Унҗиде яшемә кайттым мин,
Эзләре калса да чорларның.

Соңлаган язлардай килдең дә,
Иркәләп, моңнарда назладың.
Тургайлы таңнары кайткандай,
Бергәләп уздырган язларның.

Соклаган язлардай килдең дә,
Канатлар үстердем, мәхәббәт.
Үзгәрттең язмышны, үзгәрттең,
Мең рәхмәт, мәхәббәт, мең рәхмәт!

ӘЙТМӘ, БЕЛӘМ

Керфекләрең кояш нурларыдай,
Күзкәйләрең зәңгәр күлләрдәй.
Карашларын тамчы гөлләредәй,
Иреннәрең туган чиядәй.

Кайдан алдың шундый гүзәллекне,
Юк бит синдәй сылу дөньяда?-
...Әйтмә,
Беләм.
Аның барысын да
Бүләк итте сиңа Җир-ана.

Бел кадерен җирнең...
Һәм үзеңнең!..

ЗӘҢГӘРЛЕГЕ СИНДӘ

Киеп узсаң зәңгәр күлмәгеңне,
Күлдәй, күктәй булып китәсең.
Нигә инде шулай, үзәгемне өзеп,
Турыбыздан көн дә үтәсең?

Зәңгәрлеге синдә күгебезнең,
Зәңгәрлеге талгын суларның.
Гомер буе эчәр, сулар идем
Барлык зәңгәрлеген шуларның.

ҖЫР ЯЗДЫМ

Сиңа дип чәчәкләр үстердем,
Зәңгәрләр — гел синең күзләрең.
Гөлләрем шау чәчәк аталар
Язларын, җәйләрен, көзләрен...
Сиңа дип шигырьләр атадым,
Иң назлы, иң татлы язларым...
Гел сиңа охшатып каршылыйм,
Озатам сиңа кыр казларын...
Мин сине йөрәктә саклыймын,
Әйтмичә сиңа мин, гүзәлем...
Мин сиңа җыр яздым,
Җыр яздым,
Җыр яздым сиңа мин, түзмәдем...

АЛСУЛЫК

Алсу тынлык кунган офыкларга,
Алсу моңга чумган эңгерләр.
Йөрәкләрне җилкендереп ала
Алсу кичтә алсу мизгелләр.

Болыннарда алсу ромашкалар
Нидер сөйли талгын җилләргә.
Алсу чыклар тамып-тамып төшә
Алсу томан кунган җирләргә.

Алсу уйлар, алсу хыял ага
Салмак кына алсу елгада.
Алсу кичләр, алсу таңнар белән
Без яшибез әле дөньяда...

Шул алсулык безнең төнебезне,
Көнебезне бергә бәйләсен.
Алсу иннек сөрткән офыкларда
Дөрләмәсен афәт шәүләсе.

ЯЗЛАР БҮЛӘК ИТТЕ

Һәркөн саен зарыгып көтәм кичне,
Кич җиткәч тә — синең килүне.
Язлар бүләк итте сөелүне,
Язлар бүләк итте сөюне.

Шул язларга кат-кат рәхмәт укыйм,
Шул кичләргә мең кат табынам.

Сүнәр учакларым дөрләп китте —
Йөрәгемә утлар кабынган.

СЕРЛӘРЕҢНЕ СЕРДӘ САКЛАДЫМ

Серләреңне мина сөйли идең,
Чәчләремнән сыйпап, иркәләп.
Аерылганда, тик сер итеп кенә:
Сөям,— дидең язгы иртәдә.

Серләреңне миңа сөйли ндең
Унҗиде яшь ишек какканда.
Сер,— дип кенә бит очымнан үптең,
Инешләрдә бозлар акканда.

Хыялландык. Истә, Онытa алмыйм
Кавышулар вәгъдә иткәнне.
Серләр калды сердә,
Беркем белми
Бер-беребезне һаман көткәнне.

Бүген дә мин кайтам яшьлегемә,
Сер саклаган туган якларым...
...Сөю хисе тулы йөрәк әйтә:
Серләреңне сердә сакладым,
Серләреңне сердә саклармын.

СИҢА

Нәрсә бүләк итим диеп
Йөрдем уйлап —
Йолдызларны чүпләдем мин
Күкләр буйлап.

СИҢА ӘЙТЕР СҮЗЛӘРЕМ КҮП

Сиңа әйтер сүзләрем күп —
Әйтә алмыйм,
Юк кыюлык.
Бары шуны гына аңла:
Синнән башка
Тормышым юк.

Сиңа әйтер сүзләрем күп —
Әйтә алмыйм,
Сөйләр күзләр.
Онытa алмыйм карашыңны:
Синең күзләр —

Зәңгәр күлләр.

Сиңа әйтер сүзләрем күп,
Җитми икән
Кыюлык ник?
Мәхәббәтем карап тора
Күрерме дип,
Танырмы дип.

ЯКТЫ ШИГЫРЬ

Яз кояшлы җирдә.
Гөрләвекләр
Язгы ташкын булып йөгерә.
Якты көннең якты бизәкләрен
Алып була хәтта өлгегә...

Шундый вакыт бу яз: бөтен дөнья
Шатлык, сөенечкә уралган.
Күршем әнә «орчык» улы белән
Хозурланып йөри урамда.

Нарасый җан — сабый күккә карый,
Ал кояшка суза кулларын.
Ал кояшка кулын суза-суза
Үсеп килә минем улларым.

Ике улым — ике якты күзем,
Якты киләчәккә төбәлгән.
Безнең җаннар инде дүрт дистә ел
Яктылыкка карап өйрәнгән.

Үткәннәрне онытуым түгел,
Алар күңелемә уелган.
Җанга якты сирпеп, балкып тора
Ике улым минем уемда.

Дөньяда яз.
Дөнья шундый матур,
Матурлыкка бар җир уралган.
Күршем улына нидер сөйли-сөйли,
Кайтып килә әнә урамнан.

Сабый бала зәңгәр күккә карый,
Ал кояшка сузып кулларын.
Әй киләчәк!

Якты нурлар булып
Тоташалар сиңа уйларым...

ТӘРӘЗӘДӘ НИЛӘР БАР?

Төнге тынлык,
Биш катлы йорт,
Тәрәзләрдә ут яна.
Шатлык тулы бер тәрәздән
Җыр тарала дөньяга.

Бер тәрәздән оран сала
Яңа туган нарасый.
Якты көнгә күз салгандай,
Утка текәлгән сабый.

Бер тәрәздә кайгы уты —
Куя кеше дөньяны...
Тәрәзәләр нидер сөйли,
Тик аңлыйбызмы аны?..

Тәрәзләрдә якты утлар —
Уйлар уйларны сүтә:
Кемдер килә, кемдер китә,
Ә яшәү дәвам итә.

ЧҮКЕЧ ЧЫҢЫ

Аргы урамнан чын-чаң, чың-чаң
Ишетелә чүкеч чыңы.
Шул авазлар хәтерләтә
Чабаталы балачакны.

Алачыкта без, сабыйлар,
Чиратлашып күрек тарттык.
Шул чүкечнең чыңнарыннан,
Моңнарыннан ләззәт таптык.

Төрәннәрен сукаларның
Таптый иде олы чүкеч.
Сандалларда чын-чан итеп
Җырлый иде кече чүкеч.

Балачакта чүкеч чыңы
Күңелләргә сеңеп калган.
Чын-чаң, чын-чан.
Шул чыңнарны

Бүген менә җырга салам.

ЗУР КӨРӘШТӘ ӘЛЕ БҮГЕН ДӘ

Басуларым — арыш дулкыннары,
Болыннарым — чәчәк бәйләме.
Күптәнме соң дөнья бәйрәм итте
Сагынып көткән Җиңү бәйрәмен.

Күптәнме сон дөнья бәйрәм итте,
Ә күптәнме җирләр тетрәде?
Һәркем белә: сугыш теләүчеләр
Җир йөзендә әле бетмәде.

Көрәшәбез, изге җиребезне
Үлем, хәсрәт, каннар күммәсен.
Яралары сызлап торган җирем
Сугыш афәтләрен күрмәсен.

Алсу таннар сызылып атсын диеп,
Кояш көлсен өчен күңелдә.
Яралары сызлап торган җирем
Зур көрәштә әле бүген дә.

ӘНКӘЙГӘ

Ник кайтмый соң, ул-бу юк микән, дип,
Борчыласың, әнкәй тагын да.
Бүген дә мин туган нигеземә
Кайтам, әнием, синең янына.

Таныш мина капка ачылуы,
Ишек шыгырдавы күптәнге.
Улым кайтты, диеп, бик тиз генә
Самоварын куеп җибәрде.

Учагында дөрләп утын яна,
Каз итеннән шулпа өлгерә.
Сыйлыйм әле төпчек улымны, дип
Арлы-бирле әнкәй йөгерә.

Утыр әле, әнкәй, яннарыма,
Сине кургәч, ашау онтыла.
Ни хәлен бар?
Ачуланма инде,
Сирәк кайтам туган йортыма.

Сәламәтлек ничек, сөйлә, әйдә,
Тавышыңны зармын тыңларга.
Оныткан, дип рәнҗи күрмә берүк,
Сине уйлыйм туар таңнарда.

Менә, әнкәй, салкын кыш та үтте,
Сандугачлы язлар килделәр.
Тургайларсыз язлар булмаган күк,
Һәрчак синдә безнең күңелләр.

КЫЗЛАР, КЫЗЛАР

Ватан сугышы чоры кызларына

Кызлар, кызлар,
Сезгә ни әйтсәм дә,
Бик аз булыр төсле күренә.
Комбинезон кигән буй-сыныгыз
Зифа талдай калды күңелдә.

Тракторын йөртте, иген икте,
Бары җиңү булды уенда.
Арган күңелләргә дәрт өстәлде,
Кичен кызлар килгән уенга.

Кызлар, кызлар,
Үтте яшьлегегез
Фермаларда, завод, кырларда.
Сөю сүзен сез бит ишеттегез
Ул чакларда бары җырларда.

Кызлар, кызлар,
Җиңү язы килде.
Ир-егетләр яудан кайттылар.
Тик кайтмады узган яшьлегегез,
Агым судай агып киттеләр.

Кызлар, кызлар!
Сезгә ни әйтсәм дә,
Бик аз булыр кебек күренә.
Каршы чыгып көткән чакларыгыз —
Ак каендай калды күңелдә.

Рәхмәт сезгә, кызлар!..

ӘЙЛӘНЕП КАЙТТЫЛАР
Җырланып бетмәгән җырлар бар,
Сөйләшеп бетмәгән сүзләр бар.
Сөрелеп бетмәгән җирләр бар,
Сөелеп туймаган күзләр бар.

Өзелеп-өзелеп көтеп тә
Кавыша алмаган ярлар бар —
Ядрәдән киселгән егетләр
Җир кочып егылып калганнар.

Шул җирдә калыккан чәчәктән
Болыннар, үзәннәр балкыйлар.
Әйтерсең гөл булып батырлар
Өйләргә әйләнеп кайттылар...

ТАЛЬЯН ГАРМУН
Кулларымда тальян гармун чыңлый —
 Әтиемнән калган истәлек.
 - Зур үс, улым, тальянымны сакла,
Бу гармунда минем хисләрем,—
Дигән сүзе тальян моңы кебек,
Колагымда тора гел минем.
Иртә-кичен шуны көйлимен мин,
Аннан моңлы көйне белмимен.

Тальян гармун озата барды яуга,
Тальян гармун тылда уйнады.
Тальян гармун Җиңү маршын көйләп,
Урамнарны иңләп буйлады.

Сагынганда алам кулларыма,
Шул тальянны сузам кичләрен.
Чишмәләрдәй көмеш моңы сөйли
Әтиемнең кайнар хисләрен.

АВЫЛ ЧИШМӘСЕ
Авылымның чылтыр чишмәсе бар,
Чәйгә суы бигрәк килешә.
Таңнар белән шунда суга килә
Алсу, Банат, Сара һәм Гайшә.
Авыл карты аны тәрбияләп,
Карап торды гомере буена.
Рәхәтләнде авылымның халкы
Җанга рәхәт татлы суына.

...Күптән түгел шул чишмәгә килдем:
Таш-кирпечтән чишмә киенгән.
Тирә-ягы яшел рәшәткәле,
Тал-тирәкләр аңар иелгән.
Йөрәк тибәмени! —
Салкын суы
Бәреп тора ап-ак ташыннан.
Кем төзәткән? —
Шуңа рәхмәт әйттем
Түбәтәем салып башымнан.
Авылымның чылтыр чишмәсе бар
Көч-хәл өсти эчсәң сулары.
Шул чишмәдә очрашадыр кебек
Кешеләрнең гомер юллары.

ХӘБӘР КӨТӘМ ҺАМАН
Каршы чыгам, иркәм,
Кайтыр юлларына.
Сагыш хисе тулы
Чәчәк кулларымда.

- Көт мине, көт,— дидең,
Чәчләремнән сөйдең.
Үзең белән алдың
Йөрәгемне минем.

Язмышта ни язган:
Яшьлек көтеп узган.
Көттем сине көздән,
Көттем кыштан, яздан.

Саубуллашкан көннән,
Узган кырык бердән,
Хәбәр көтәм синнән,
Хәбәр көтәм җилдән.

Хәбәр көтәм җырдан,
Хәбәр көтәм җирдән,
Ник кайтмыйсың, иркәм?..

Каршы чыгам көн дә
Киткән юлларына.
Сөю хисе тулы
Чәчәк кулларымда.

Шул гөлләрне учлап,
Сибәм юлларыңа:
Киткән юлларына,
Кайтыр юлларына...

КӨТ СИН, АНА

Тан әтәче кычкыра дүртенче кат,
Сукты сәгать инде дүрт тапкыр.
Таңга карап, ана улын көтә,
Син кайгырма, ана,
Ул кайтыр.

Хәбәр килми, диеп үпкәләмә,
Бәлки, юктыр вакыты язарга.
Авыргандыр,
Белгертәсе килми,
Ышан, кайтыр шушы язларда.

Туган җирдән, әниләрдән башка
Ни ямь бар соң, әйтче, бу җирдә?
Үпкәләмә, ана,
Рәнҗемә дә аңа,
Кайтыр әле улың бер таңда.

Күкрәк сөтен бирдең,
Авырлыкны җиңдең,
Кыенлыклар аша атладың.
Син дә шулай
Улың,
Илдән башка
Иң газизне җирдә тапмадың.

Ана, бала, халкым, туган җирем.
Бер-берсенә алар бәйләнгән.
Аерып булмый,
Давыл, ут, су белән
Көйгә салган җырга әйләнгән.

...Таң әтәче кычкыра бишенче кат,
Сәгать сукты янә биш тапкыр.
Юлга чыгып ана улын көтә,
Көт син, ана,
Тиздән ул кайтыр.

ИЛЕМ ТАНЫ

Чулпан йолдыз батты, таңнар атты,
Якты нурлар җирне аклады.
Уяндылар кырлар, яңгырады җырлар,
Сандугачлар таңны мактады.

Мәрҗән сыман көмеш таң чыклары
Чәчәкләрне кочып үптеләр.
Җирнең иминлеген барлагандай,
Талгын җилләр исеп үттеләр.

Ал кояш та керфекләрен ачып,
Гәүһәр нурын сипте үрләргә.
Бүз тургайлар назлы моңнар илтте
Төнбоеклы көмеш күлләргә.

Күбәләкләр кырга китә очып,
Бал кортлары — матур болынга.
Ни җитә соң туган як таңына,
Мактыйм шуны җырлар җырымда.

САГЫШЛАРНЫ БАСА АЛМАМ

Торган җир әйбәт булса да,
Яхшырак туган якта.
Авылымның таңнары да
Үзгә, үзгәрәк ата.

Яшьли йөргән сукмаклардан
Килә тагын үтәсе,
Айлы кичтә күл буенда
Хыялларны сүтәсе.

Күктә балкый түгәрәк ай,
Шәүләсе төшкән суга.
Сагынып гомерем үтәрме,
Сагышка калдым шуңа.

Сагышларны баса алмам,
Кайтмыйча туган якка.
Алтыннарга күмелсәң дә,
Авылым үзенә тарта.

...Ак томаннарга төренеп,
Тездән чык ярып кайтам.

Сагышларым — якты сагыш —
Гомеремне озайта.

КҮҢЕЛЕМ — УТЛЫ КҮМЕР

Коймак пешәдер мичләрдә —
Төтен чыгара өйләр.
Алсу таңнар атып килә,
Тарала таныш көйләр.

Хезмәт көе, хезмәт җыры
Яңгырый таңнар белән.
Иркен болын кочагыннан
Нур ярып кайтып киләм.

Төне буе атлар көттек,
Бергә-бергә ай белән.
Җәйге таңнар әйтерсең лә
Яшьлектән кире килгән.

Яшьлегемдәге тургайлар,
Яшьлектәге болыннар,
Яшьлектәге арыш кыры,
Яшьлектәге — колыннар.

Тик аерма фикерләүдә,
Аерма бер караштa.
Аерма бар яшьләрдә дә,
Башкарак уйлар башта.

Күп нәрсәдә бар аерма —
Үтелгән байтак гомер...
Картайсам да янам әле,
Күңелем — утлы күмер.

АК КАЕННАР

Минем туган якларымда гына
Шулай шаулый кебек каеннар.
Алар арасында зарыгып көткән,
Без утырткан бер пар каен бар.

Менә бит ул безнең яшьлегебез —
Чуклы шәлен салган иңенә.
Рәхәтләнеп бөдрә чәчен тарый
Туган якның назлы җилендә.

Ак каеннар шаулап үсә һаман,
Икебез дә аңар гашыйк без.
Ул гүзәлләр җирдә назланганда,
Бәхет күкләренә ашыйк без...

Мөлдерәмә тулган күңел күле,
Шатлык булып җиргә ташыйк без.

ТУГАН АВЫЛЫМ

Синең белән кавышуны
Мин сагынып көтеп алам.
Камышлар курай тарта да
Күңелгә моңнар сала.

Җырдан тынмый чишмәләрең,
Инешләрең — ил яме.
Зәңгәр күктән тургай җырын
Туялмыйча тыңладым.

Урманында кәккүкләрең
Эндәшә гомер санап.
Мин үлемсез бугай синдә
Туктамый кәккүк һаман.

ИГЕНЧЕНЕ ЗУРЛЫЙМ

Авылымда тудым, авылымда үстем.
Беркая да аннан китмәдем.
Күкрәгемә терәп кисәм бүген
Үзем иккән арыш икмәген.

Тартканнарны шәһәр тартсын әйдә,
Мин мәңгегә җиргә бәйләнгән.
Арыш серкә очыруы минем
Күнелемдә җырга әйләнгән.

Мин — игенче, игенчене зурлыйм
Басуларны иңләп кайтышлый.
Буразнадан башка тора алмыйм,
Игенчегә
Барлык җырларымны багышлыйм.

КЕШЕ ГОМЕРЕ

Кеше гомере — диңгез комнарыннан
Дулкын юып алып киткән эз.

Кеше гомере — мәдхиягә кергән
Иң нарасый, садә, зифа сүз.

Кеше гомере күктә янып сүнгән
Метеоритка кайчак тиң була.
Кеше гомере галактикаларга
Кайчак сыя алмас киң була.

Кеше гомере — моңлы җыр да була,
Чиксез мәңгелеккә узасы.
Ни булса да, кеше исән чакта
Үз гомеренең үзе хуҗасы.

ЧЫКСАМ ӘГӘР
Чыксам әгәр иркен басуларга,
Тургай җыры чынлый колакта.
Язлары да безнең кызлар кебек
Бигрәк назлы инде бу якта.

Буразналар кояш назлавыннан
Кара икмәк кебек күперә.
Басуларга чыксам, йөрәккәем
Бәйгедәге аттай җилкенә.

Тракторлар, тагып чәчкечләрен.
Гәрәбәдән бодай чәчәләр.
Бар җиһан уянган, кара инде.

Шытып чыккан матур чәчәкләр.
Тормыш кайный җирдә,
Тургайларның
Яңгырыйлар шатлык җырлары.
Күкрәк тутырып сулыйм,
Хезмәтемнән
Яшәрәләр илем кырлары.

Нинди рәхәт канатланып яшәү
Өмет тулы изге бу җирдә.
Шушы гүзәллекнең хуҗасы мин
Рәхмәт укыйм туган җиремә.

БУРАЗНАЛАР, ИГЕН КЫРЛАРЫМ
Урманнарым мамык шәлен япкан,
Киң кырларда ап-ак юрганнар.
Шул кырлардан тәүге тапкыр бабам,

Атам, анам озын юл алган.

Басуларда иген шаулап үсә,
Шул кырлардан илһам, көч алам.
Тугайларым, сыр-сыр буразналар,
Сездән башка, юк, һич торалмам.

Буразналар сыздым,
Бергә тезсәң,
Экваторны ничә әйләнер? —
Шул кырлардан, шул басудан башка
Күңелем буш минем нигәдер.

Кар астында минем буразналар
Әле изрәп йоклап яталар.
Озакламас, бар җиһан уяныр,
Иркен кырлар чәчәк атарлар.

Буразналар сөттәй пар чыгарыр,
Уҗымнарым дәррәү калкырлар.
Киң кырларны кочып үбәм, сөям
Һәм сөенәм — минем хакым бар.

Буразнада тапкан мине анам,
Кендек әби булган Җир-ана.
Җирдә тудым,
Тормыш юлым минем
Шул буразналардан башлана.

Китәсем юк сездән аерылып,
Ишетәсезме, басу-кырларым!
Гомеремне сезгә багышладым,
Сезгә булсын туар җырларым.

БУЛ ХУҖАСЫ ТЫНЫЧЛЫКНЫҢ, ҖИРЕМ!
Утлы кылыч белән күкне телеп
Яшьни-яшьни, шаулап, күкрәп,
Килеп житте менә тагын язым —
Хуш исләргә тулды күкрәк,
Энҗе тамчы булып яуды.яңгыр,
Чәчте нурын Кояш-асыл.
Бәрхет чирәмнәрдә иркәләнеп
Уйный егерменче гасыр.
Тансык моңнар — кош-корт авазлары,
Бар табигать уйный моңлы сазын.

Кочагына алды камышлыклар
Сагынып кайткан үрдәк-казын.
Санап булмый Җирнең изгелеген.
Ул нарасый, садә, түзем.
Зиһеннәре томаланса кешелекнең
Һәм капланса әгәр күзе,
Күчәреннән чыгуы бар Җирнең.
Аек акыл кирәк җирдә шуңа...
...Һәр ел саен килсен язлар.
Үрдәкләрен көтсен камышлары,
Камышларын сагынып кайтсын казлар.
Янгыр яусын энҗе бөртек булып,
Чәчсен нурын Кояш-асыл.
Йомшак басып хәтфә чирәмнәрдән,
Килсен утызынчы гасыр.

ТУГАН ЯК КӨЗЕ

Алтынсу төс усак, каеннарда,
Басуларда сыр-сыр буразна.
Болыннарда чабып йөри җилләр —
Хәйран калын тордым беразга...

Күзләремдәй мөлдерәмә күлнең
Җилләр үбә җырчы камышын...
Күргән сыман булам мин шуларда
Гомеремнең кайтмас агышын.

Кыр казлары кайтыр, әнә алар
Саубуллашып китеп баралар.
Миләшләрем кызыл тәлгәшләрен
Яулык сыман болгап калалар.

Ә мин калыр идем яшел җәйдә,
Кояш нурларына ябышып.
Көзләр белән тиңләп буламыни —
Башкарак шул кеше язмышы...

Табигать гел алмашынып тора,
Язлар белән тагын яшәрер.
Туган җирнең фасыллары белән
Мин яшәрмен, мәңге яшәрмен...

ҮПКӘЛӘ

Булмый шул онытып язларны!
Язгансың сагынып аларны:

“Ташкыннар шикелле идең син ...”
Укыйм мин
Язмышлар язганны.

Беренче мәхәббәт... Ярату...
Кирәкме ярамны яңарту?
Яр таптың. Син киттең,
Мин калдым,..
Артыктыр суз белән аңлату.

Кирәкми аңлату...
Тик бүген
Аңладым сөюем артканын.
Йөрәгем,
Уйларым,
Хыялым,
Күнелем гел сиңа тартканын.

Боларның барсын да,
Барсын да
Син дә бит күптәннән аңладың.
Үпкәлә!
Ләкин мин гаепсез.
Язмышны син үзең алдадың.

ҖЫРЛА, ДИСЕҢ
Җырла, дисен,
Җырлыйм.
Минем күңел
Җырны сөя, моңны ярата.
Борчуларны җырлар тарата да,
Шатлыкларны җырлар яңарта...

Сыздыр, дисен, тальяныңны,
Сызам,
Күңелләрдән моңнар түгелсен.
Кушыл син дә, дустым,
Безнең җырлар
Зәңгәр күккә таба үрелсен...

Басу-кырны урап кайтыйк әле,
Басулар да җырны тыңласын.
Безнең кырлар — безнең гомеребез,
Аларны да моңнар чорнасын...

Җырлыйк әле, дустым, җырлыйк әле,
Бөтен дөнья моңга күмелсен,
Йөрәгендә ята синең моңнар,
Син бит, дустым, моңсыз түгелсең...

Игенчедән шәп җырчы юк җирдә, -
Һәм шагыйрь юк аны уздырган.
Синең җырың — мәңге бетмәс җыр ул.
Бураэналар булып офыкларга,
Киләчәккә таба сузылган...
Җырла, дисен,
Җырлыйк әйдә бергә!..

АЧУЛАНМА

Ачуланма,
Соңга калып килдем...
Яшьлегемдә бер кат югалттым.
Очрашырбыз әле бу дөньяларда дип,
Үз-үземне күпме юаттым.

Юатуын юаттым да кебек,
Сизмәдем шул гомер узганын,
Маңгай-биткә онытылмаслык итеп
Еллар бураэналар сузганын.

Ачуланма,
Соңга калып килдем...
Көткәнсең бит мине сагынып,
Кошлар кебек очып килдем менә
Әсәрләнеп, канат кагынып.

Ачуланма, соңга калдык диеп...
Ачуланма, башка югалтмам.
Очрашырбыз бу дөньяда диеп,
Үземне мин һичбер юатмам.
Ачуланма,
Соңга калып килдем...

ҖЫРЛАРЫМНЫ ӘГӘР ОТЫП АЛСАҢ

Җыр язуны җиңел дисенме син?
Җыр язуның беләм газабын.
Янып-көеп, зур газаплар аша
Сиңа атап җырлар язамын.

Җырларымны отып алырсыңмы,
Сиңа диеп аны җырласам.
Сагышларны, барлык моң-зарларны
Шул җырларны җырлап гел басам.

Җырларымны җырла әле, иркәм,
Моңсуланып кояш батканда.
Җырларымны җырлап уян әле
Алсу таңнар сызылып атканда.

Җырларымны әгәр отып алсаң,
Җилләрдә син аны ятлама.
Сөюләрең әгәр керсез булса,
Әйләнеп кайт туган якларга.

СОРАУ БИРӘ ДУСЛАР

Сорау бирә миңа очраган дус;
«Шигыреңдә кырны язасың,
Авылыңны, болын, әрәмәлек,
Язасың син Сәет абзасын.

Гөлҗимешен, балан, бөрлегәнен,
Язасын син печән, күрәнен,
Авыл халкы күңелеңә якын,
Этләрен дә якын күрәсең.

Һәр нәрсәгә карап сокланасың,
Каян килгән шундый ярату?
Бик яраткач, ник тормыйсың шунда,
Кыендыр ул яшәү җан атып.

Мич ягасы, суга барасы юк,
Барлык эшең өйнең эчендә,
Концерт-театрга йөреп була,
Ял итәсең хәтта эшеңдә».

Ни дип җавап бирим?
Ни әйтсәм дә,
Аңлаталмам кебек сезгә мин.
Шәһәрне мин һич тә яманламыйм,
Җайлы тормыш аннан эзләмим.

Авыл басуларын сагына-сагына
Яшәлгән шул инде, яшәлгән.

Мин бүгеннән кайтып җитәр идем,
Тик хатыным, дуслар, шәһәрдән...

Ир — баш, хатын — муен дигән сүз ул,
Иң дөрес сүз, элек-электән.
Муен борылмаса, баш нишли сон?
Шул муенга башым береккән.

...Үсеп кенә җитсен Марат улым,
Мин агроном аны итәрмен.
Шул кырларда улым иген игәр,
Мин моң булып кайтып җитәрмен...

СИН ГЕНӘ

Тугайларда йөрдек, шаярыштык-көлдек.
Болыннарда хуш ис бөркелә.
Йөрәгемнең минем иң түрендә, Гөлем,
Бөреләнгән бары син генә,
Күрше кызы — чибәр Гөлгенә.

Бакчаларда нәркис хушбуйлана,
Ләйсән яңгыр җиргә сибелә.
Мәхәббәтем чәчәк атты язда,
Күңелемдә бары син генә,
Карлыгачым минем, Гөлгенә.

Алтын көз дә җитте,
Чәчәк сулар инде,
Ак томаннар иңгә сарыла.
Иртә яздагыдай, гөлем гүзәл һаман,
Киләчәгем бары син генә,
Шаян кызый, матур Гөлгенә.

Күптән ап-ак һава,
Күктән мамык ява,
Тибрәлдерә аны җил генә.
Язны көтә күңелем,
Мәхәббәтем, Гөлем,
Сөенечем бары син генә,
Яшьлек дустым — гүзәл Гөлгенә.
Син генә!..

КӨМЕШ КАРЛАР ЯВА

Карлар ява көмеш тәңкә сыман —
Балачактан килгән карлардай.

Әкиятләр укып,
Хыялларда йөзен,
Без бит бергә үскән балалар.

Карлар ява. Җизсез тыныч һава—
Әй йөрибез бергә урамда:
Олы урам малайлары түгел —
Ир-егетләр уйный буранда.

Җыелыштык бергә. Җәен түгел,
кышын -
Балачакта шулай сөйләштек.
Кырык яшьлек ирләр карлы кичтә
Сабыйлардай көлдек, серләштек.

Кызларыбыз кая? Алар унау иде...
Кызлар кайтыр килер язларда.
Нәркисләрем хуш-ис таратканда,
Шомырт чәчәкләре яуганда.

Алар кайтыр язлар белән бергә —
Кыр казлары очып кайткандай.
Барыбыз да булыр бер мизгелдә
Яшьлегебез ишек каккандай.

САРЫ КҮРСӘҢ...
Сары күрсәң,
Сагыш булыр, диләр,
Сары яфрак күрдем төшемдә —
Күзләр җиткән,
Басуларда салам,
Гәрәбәдәй бодай көшелдә.

Сары күрсәң,
Саргаерсың, диләр,
Сары лимон күрдем төшемдә —
Рәхәтләнеп җырлап күңел ачтык
Кызыл туйда якын күршемдә.

Сары күрсәң,
Хәсрәт килер, диләр,
Җиз акчалар күрдем төшемдә —
Лотерейга автомобиль оттым
Кичә генә, дуслар, өнемдә...

ИЗГЕ ҖИР

Җиргә тама яңгыр, яшьләр,
Җиргә ява ак карлар.
Җирдә яши ялгызаклар,
Яшиләр җирдә парлар.

Җирдә шатлык, җирдә кайгы,
Җирдә тынычлык, сугыш.
Җирдә гөлләр, җирдә бомба —
Кысыла иркен сулыш.

Җирдә дөреслек һәм ялган,
Җирдә дошман һәм дуслар.
Җир мәхәббәт һәм нәфрәтнең
Барысын бергә кушкан.

Кушкан да, тарта җанына
Барысын сыйдырган Ана.
Без шуңа да Җир-Ана, дип,
Эндәшәбез шул аңа...

Аналар барысын да белә,
Аналар күңеле сизгер...
Җир кебек изге Аналар,
Җир — аналардай изге...

ИГЕНЧЕГӘ

Чыгам да кырларга, сокланам:
Җыр җырлый күкләрдә тургайлар,
Һич бетмәс көч бирә, дәрт өсти
Басулар, урманнар, тугайлар.

Чыгам да кырларга, сокланам,
Башаклар тирбәлә саф җилдә.
Игенче, горурлан, хезмәтең,—
Иң бөек, иң даһи бу җирдә.

Чыгам да кырларга, уйланам:
Игенче, син изге, хикмәтле.
Туган ил сүзенә тиң сүзләр:
Тынычлык, игенче, икмәктер...

АЛТЫН КӨЗЕМ

Җиргә төшә сары, ал яфраклар,
Көз җиткәнен алар белдерә.

Алтын көзең синең, туган ягым,
Күңелемә якын, бер генә.

Басуларым инде бушап калган;
Икмәкләре кергән амбарга.
Алтын көзем.
Ямансулый алмыйм,
Юксына ла алмыйм син барда.

Һәркайда да муллык, кызыл туйлар,
Һәрбер җирдә көзге шатлыклар.
«Кара көз» дип сиңа беркем әйтмәс,
Кочагыңда — муллык, байлыклар.

Хуш киләсең, әйдә, алтын көзем,
Көтеп алдык кыш, яз, җәй аша.
Безнең язмыш килер язмышларга
Шундый көзләр аша тоташа.

КҮҢЕЛЕМДӘ ШИГЕМ

(Миха Квливидзедән)
Күңелемдә шик бар болыт кебек,
Әче җилләр исә сызгырып.
Кочагыма керче,
Җылытырмын,
Таңнар атар, иркәм, сызылып.
Хисләремдә йөз син аккош кебек,
Серләреңне шунда ачарсың,
Хыялларны ике канат итеп,
Бәхет киңлегендә очарсың.
Йөрәгемне ачам.
Тиз кер, тиз кер инде—
Үз өеңә кергән шикелле...
...Тулган иреннәрең тараттылар
Күңелемдә туган шигемне.

ТӨШТӘ КҮРДЕМ

(Миха Квливидзедән)
Төштә күрдем:
Кире кайткансың нда,
Иркәлисең мине, үбәсең.
Күзләремнән мәрҗән чыклар тама,
Яратамын икән, күрәсең...
Тәмле төшне үзде телефонның
Чылтыравы

Ниләр әйтмәдең:
Янадың да, куркытып тп алдың,
Ачуландың,-
Бер сүз дәшмәдем.
Барсына да түзәргә мин риза:
Каргышына, сүгү, тиргәүгә.
Тик төшемне күреп бетерәсе иде
Яшьләр тамган мамык мендәрдә.

БҮЛӘК ИТТЕМ ТАҢНЫҢ...
Таң чыкларын иртән
Бүләк иттем, иркәм,
Алар чөнки керсез, пакь чыклар.
Кочып сиңа бирдем
Тан җилләрен җирнең,
Чөнки иртән җилләр саф чаклар.

Чәчәкләрен таңның
Бүләк иттем тагын,
Зәңгәр күзләреңә мин тиңләп.
Көмеш күлне сиңа
Бүләк иттем, миңа
Йөзәр өчен таңда гел иңләп.

Таңда сайрар кошлар —
Тиңдәш сиңа алар.
Бүләк иттем аның моңнарын.
Барлык тойгыларым
Бүләк иттем таңда,
Онытмасын, дидем, мин барын.

Йолдызларны күктән
Итмәдем мнн бүләк,
Чөнки алар салкын, ераклар.
Җир җылысын бирдем,
Бергә булыйк, дидем,
Типсен бергә каннар йөрәкләр.

Таң суларын алып
Чылтыр чишмәләрнең,
Бирдем сиңа таңда эчәргә.
Матур гөлем, шуңа
Язган нкән миңа
Синең белән тормыш кичәргә.

КЕМ ИКӘН УЙЛАРЫНДА?
Суга бара матур кызлар,
Вак-вак атлап, вак-вак атлап.
Сукмакларда җәелеп яткан
Хәтфә чирәмнәрне таптап.

Иңнәрендә чиләкләре
Бик килешә буйларына.
Суга бара, суга алар,
Кемнәр икән уйларында?

Кайберсенең сөйгән яры Армиягә китеп барды.
Сара,
        Алсу,
                Банат,
                        Зәйнәп
Ак яулыклар болгап калды.
Язган хатлар аккан сулар
Белән инде тиңләштеләр.
Банат,
        Зәйнәп,
                Алсу,
                        Сара
Бергәләшеп серләштеләр.

Сара әйтә:
Зариф миңа
Атнага ике хат яза.
Хезмәт итәм отличнога,
Яшәп ятам исән-таза.

Алсу да керешә сузгә,
Чөнки аның Әхмәтҗаны
Көн саен бер хат җибәрә,
Бигрәк уңган сөйгән яры.

Ник керешми сүзгә Банат,
Әллә бер-бер хәл булганмы?
Юк, берни булмаган аңа,
Тик юксына Гыйльмулланы.

Зәйнәбе бигрәк то шаян,
Һәрбер сузе чәнечкеле.
Гариф язган: «Әзерләп тор

Кәтлит белән чәнечкене.

Өйрәнеп киттем мин монда
Ашарга гел кәтлит кенә».
Зәйнәп яза җавап ана:
«Сау йөреп кайт, Гариф, җаным,
Суыртырмын кәнфит кенә».

Суга бара матур кызлар,
Вак-вак атлап,
Вак-вак атлап.
Сукмакларда җәелеп яткан
Хәтфә үләннәрне таптап.

Иңнәрендә чиләкләре
Килешә соң буйларына.
Суга бара, суга бара,
Әнә кемнәр уйларында.

ЮКСЫНАМ, ДИСЕҢ СИН

Нигә сон юксынам, дисең син?
Әйләнеп кайт әле бу якка.
Гомерең уза бит,
Чем-кара
Чәчләрен буялган ап-акка.

Юксынып узгандыр көннәрең,
Сагына утырткан каенның.
Туган йорт нигезен күрмичә
Торганның күңеле кайгылы.

Күзләрең ямансу, боеклар.
Алар да авылны сагына.
Әйләнеп кайт әле бу якка.
Кайгырма, моңайма, юксынма.

Саф чишмә сулары, һавасы,
Тугае, болыны, урманы
Кочаклап алырлар үзеңне —
Шулардан кадерле җир бармы?

Юксынам, дисен син,
Гомернең
Саныйсы көннәре күп әле.
Туган як туфрагын сагынып,

Әйләнеп авылга кайт та син,
Шифалы җилләрен үп әле.
Ә яшәү нинди шәп — күр әле!..

ТОЛЫМБАЙ

Казахларга дала канат куя —
Ут уйнатып куа чаптарын...
Азга гына уйга калам икән,
Искә төшә солдат чакларым.

Әй син, казах,
Якын дустым минем,
Килеп җитә идең яныма.
Теш елтыратып,
Керсез елмаюың
Яллар бирә нде җаныма.

Сөйли идең:
Дала ни пышылдый,
һавадагы тургай ни җырлый?
Күл буенда камыш ниләр сөйли,
Искән җилләр таңда ник елый?

Күл буенда камыш көйгә салган
Үткәннәрнең авыр газабын.
Киң далалар сөйли,
Тургай җырлый
Гүзәллеген мактап заманның...

Кулга корал тотып,
Сакта тордык
Ил чигендә бергә, Толымбай.
Бик дус идек,
Шаһит булды аңа
Якты кояш белән тулы ай.

Өч ел буе бер кашыктан ашап
Гомер иттек, абый-эне без.
Дошманнардан илне сакладык без
Аяз булсын өчен күгебез.

Казах дустым, син еракта инде,
Тик һаман да хатлар киләләр. «Татар дустым,
Күңелләрем сине
Сагына шул бигрәк?—дияләр.—

Кил кунакка,
Кымыз,
Мәйләр белән,
Бишбармаклар белән сыйлармын.
Уйлыйм сине сызылып таң атканда,
Көтәм сине,
Якын туганым.

Көтәм сине,
Көтәм,
Килми калма,
Сине көтә сыйлы табыннар.
Язын килалмасаң.
Көз килер дип,
Көтеп калган якын дустың бар.
Сәлам белән сиңа, Толымбай.”
...Казахларга дала канат куя —
Ут уйнатып куа чаптарын.
Искә төшә казах даласында
Тулпар атта ярсып чапканым...

ҮКЕНМӘМ
Һич үкенмәм,
Кыя түбәсенә әгәр
Менеп җитеп,
Еракларга,
Еракларга күңелем белән
Очып китеп,
Күрә алсам,
Йөрәк белән тоя алсам
Халкым моңын,
Кайгы, сагыш,
Шатлыкларын...

Үткән эздән
Сызылып калды
Ак сукмагым,..
Бер салынган
Сукмак инде
Һич күмелмәс.
Түгелсен тир,
Ул сукмакны салыр өчен
Бөгелсен бил —
Болар өчен
Үкенмим гел.

Тап-тар гына
Булсын әйдә
Сызган юлым.
Салган юлны
Тоя, дуслар,
Күңелем минем,
Йөрәгем дә әйтә кебек:
Мен кыяга.

Күзең ташла еракларга,
Еракларга!
Күңелең керсез,
Үткән юлың авыр булсын,
Туры булсын —
Халкың белән бер аяктан,
Шул сукмактан
Гел атларга.

ХУШ КИЛӘСЕҢ, ЯҢА ЕЛ!
Авырлыклар калсын иске елда,
Килеп торсын бу ел җиңеллек.
Муллык булсын,
Дус-иш артып торсын,
Күкләр аяз булсын нң элек.

Басуларда иген шаулап үссен,
Бакчаларда — алсу алмалар,
Һәр йорт саен шатлык алып килсен
Яңа елда туган балалар.

Нәфис гөлләр үссен болыннарда,
Урманнарда кәккүк моңлансын.
Җир шарына иркен тормыш килсен,
Тик сугышлар гына булмасын.

КАЙТАМ
Сагындыра,
Сагындыра икән
Сабый чакның керсез көннәре.
Яшьлегемнең, хатирәсе итеп
Саклап йөрттем айлы төннәрен.

Авылыма бүген кире кайтам,
Калды инде шәһәр юллары.

Юксындылар инде басуларны
Иген игеп үскән кулларым.

Изге җирне сөрим,
Иген игим,
Малкайларны йөртим көтүдә.
Ниләр җитә күңел тарткан җирдә
Авылыңда гомер итүгә.

Бөтенләйгә кайтам,
Киткән чакта
Гафу итче, авылым, кимсетсәм.
Кабул ит син мине, кабул итче,
Инде башка синнән мин китмәм.

КАРГЫШ
Тешләреңә кереп йөдәтермен.
Күз алдыңда һәрчак торырмын.
Онталмассын, һич тә онталмассың.
Газаплардан тормыш корырсың.
Күзен ачсаң, йомсаң да син күзең,
Күрешергә кулым сузармын.
Йөрәгеңә сагыш уты салып,
Күз алдыңнан җырлап узармын.
Газапларлар сине минем күзләр,
Һич тынгылык белмәс язмышың.
Сөюемне ятларга алмаштың,
Иң авыры — шушы ялгышың.
Әллә инде язлар җиткәндәме,
Әллә инде кышлар үткәндә...
Язмышларны пыран-заран иттең —
Барысына да үзең үпкәлә.
Язлар белән мин кайтырмын әле,
Кышлар белән киткәч язмышым.
Гомер буе үзәкләрне өзен,
Сыкрандырып торыр ялгышың.
Төшләреңә кереп йөдәтермен,
Язмышыңда мәңге калырмын.
Көн туса да, зәңгәр кич килсә дә,
Сагыш утларына салырмын.
Күз алдыңнан беркайчан да китмәм,
Кая барсаң, карап калырмын.
Гомереңнең ахырына кадәр
Һич калмыйча озата барырмын...

МИН БУЛЫРМЫН

Синең якка җилләр иссә,
Кире борма — мин булырмын.
Син булмасаң яннарымда,
Сусыз гөлдәй, гел сулырмын.

Зәңгәр күктә тургай күрсәң,
Тыңла җырын — мин булырмын.
Синең алда баш иярләр
Тук башаклар — мин булырмын.

Алсу нурлар назлар сине,
Назлан, ул наз — мин булырмын.
Челтерәп агар салкын чишмә,
Эч суларын—мин булырмын.

Болыннарда хуш ис чәчкән
Сары чәчәк—мин булырмын.
Беркөн сиңа сөю килер,
Кайнар сөю—мин булырмын.

Җил дә, нур да, чишмәләр дә
Булалмасам — ярат һаман.
Үзем генә булып калсам,
Читкә типмә — мәңгегә бул сулар һавам...

ЯШЬЛЕК

Кайда соң сез, кая киттегез сез,
Май аедай яшьлек елларым.
Узып киткән шаулы яшьлегемне
Искә алып үксеп еладым.

Яшьләр түгел, сыкрап җаннар чыга
Мөлдерәмә тулган күзләрдән.
Күнел эреп китә ишеткәндә,
Яшьлек дигән сихри сүзләрдән.

Яшьлек, яшьлек, ак яулыгың болгап,
Кай арада узып киттең соң?
Күңелләргә биреп саф мәхәббәт,
Йөрәкләргә салдың назлы моң.

Шул моңнарны җырлыйм әле менә,
Узган яшьлегемне сагынып.
Их, кайтасы иде яшьлегемә

Очар коштай канат кагынып!

ӘЙТМӘ МИҢА

Әйтмә миңа китәм инде, диеп,
Әйтми генә китсәң ни була?
Әнә инде урамнарда буран,
Эзләреңә сагыш, моң тула.

Әйтмә мина ялгыз каласың, дип,
Минем белән кала уйларым.
Уйлар — уйлар инде, чәчләремнән
Назламыйлар синең кулларың.

Җилләр йөри сагышларны барлап,
Сагыш ята синең эзләрдә.
Әйтмә миңа ялгыз калдың, диеп,
Өмет балкый әле күзләрдә.

КИТМӘ СИН

Сөйләшеп сүзләр дә бетмәгән,
Җырлыйсы җырлар да бар әле.
Китмә син үпкәләп, китмә син,
Янымда гомергә кал әле!

Сизәмсең, кошлардай ашкынып,
Сагынып яныңа киләм мин.
Күрешеп күзләр дә туймаган –
Китмә син, сөеклем, китмә син!

Китмә син йөрәкне яралап,
Әйләнеп барыбер килерсең.
Гомергә өзелеп сөярмен —
Китмә син, китмә син, китмә син!

ХАТ

Ниндидер моң чыгара чаналар,
Салмак кына куам атымны.
Ничәнче кат күңелемнән ятлыйм
Синең язган соңгы хатыңны.

Соңгы хат дип нокта куйгансың да,
Яшьләр тамган хатың өстенә.
Җитәр инде бәгърем, газапланма,
Мин килермен, тик син көт кенә!

Моң таратып карлар шыгырдыйлар,
Чана шуа ак кар өстеннән.
Карлар булып карлар эрер сыман
Сиңа булган кайнар хисемнән!

Шул хисләрне сиңа юллыйм менә,
Эретмәсме йөрәк газабың...
...Беренче кат, сөюемне әйтеп,
Сиңа шушы хатны язамын.

ӘНКӘМНЕҢ АК ШӘЛЕ

Ак мамыктан әнкәм шәл бәйләде,
Челтәр-челтәр итеп читләрен.
Әйтерсең лә шулай бәйләгән ул
Ак шәл итеп йөрәк хисләрен.

Һәр элмәге гомер юлларыдай
Сызылып ята ап-ак шәлендә,
Төшләремә керә иңнәренә
Мамык шәлен салган хәлендә.

Әнкәемнең шәлен, әнкәемнең төсен
Саклыйм һаман күңел түрендә.
Сандыгында ап-ак шәле булган
Килен булып төшкән көнендә.

Яшь чактан ук ап-ак шәл ябынган
Күңелкәе саф, пакь булганга,
Сандыгыннан челтәр шәлен алам,
Сагынудан күңелем тулганда.

ДЕКАБРЬ ДӘ ҮТЕП БАРА ИНДЕ

Декабрь дә үтеп бара инде,
Тик нигәдер карлар яумыйлар.
Карсыз кышлар кебек күңелемне
Әллә нинди уйлар даулыйлар.

Күңелем дә ярсып-ярсып ала,
Белмим, нигә шулай җилкенә.
Асфальт буйлап, яфракларны куып,
Шашып йөри салкын җил генә.

Асфаль булып , асфальт туңган,
Ә изге Җир?
Туңуыннан ничек ярылган!

Шәрә агачларга бәсләр булып
Декабрь салкыны сарылган.

Басуларда ап-ак юрган да юк,
Уҗымнарым инде туңарлар...
...Җир-ананы төреп җылытырга
Салкын карлар кирәк, туганнар.

ШӘҺӘР ЕГЕТЕНӘ

Юктыр әле синең ишеткәнен
Ал таңнарда кошлар сайравын.
Билдән чыкка батып, яшь егетнен
Моң чыгарып чалгы янавын.

Юктыр әле синең тыңлаганың
Чишмәләрнең җырлап агуын,
Күрдеңме син сөю алып килгән
Матур язлар ишек кагуын?

Җәйләрен дә әле белмисеңдер,
Көзләрен дә юктыр күргәнең.
Сөйгәнең дә, үпкәнең дә синең
Юктыр әле авыл кызларын.

Беләсеңме авыл кызларының
Җир селкетеп эшләп йөргәнен?
Кирәк икән — сөя-назлый белә,
Ярып сала кайнар йөрәген.

Көзләргә дә тиңли алмас идем,
Күңелләре бик бай булса да.
Язларга да тиңли алмам кебек,
Сөю, хисләр ташып торса да.

Үзләренә авыл кызларын мин
Тиңләр идем, бары үзенә...
...Кызлар, кызлар, нинди гүзәлләр сез,
Тик тидерә күрмим күз генә.

ӘЙ ТАЛЛАРЫМ, РӘХМӘТ СЕЗГӘ

Бөдрә таллар игән су өстенә
Үзләренең моңсу башларын.
Гел уйламам дигән идем сине,
Булмый икән — уйлый башладым.

Бөдрә таллар әллә инде шулай
Уртаклаша минем уйларны.
Сине уйлап, сине гел сагынып,
Гомерләрем шулай узармы?

Бөдрә таллар аңлый күңелемне,
Бушанам мин кайчак аларга.
Әй талларым, мең мәртәбә рәхмәт
Ярый сез бар мине аңларга...

МИШӘ БУЕ, МИШӘ ТУГАЙЛАРЫ
Мишә суын эчеп үскән яшьләр
Әллә нигә якын күңелгә.
Мишә буйларында кичләр буе
Тальян моңы җиргә түгелә.

Мишә тугайлары ямьле дә соң,
Сызылып алсу таңнар атканда.
Болынлыклар назлы моңга чума
Егет-кызлар җырлап кайтканда.

Мишә таллыклары сандугачлы,
Өздереп сайрый иртә-кичләрен.
Язын Мишә ургыгандай ургый
Сина булган сөю хисләрем.

Мишә суын эчеп үскән гүзәл
Юлларыма әгәр чыкмаса,
Сөю утларында янмас идем,
Гомерләрем буе ичмаса...

СӨЮЛӘРНЕ КИРӘК САКЛАРГА
Гөрләвекләр ага,
Йөрәк ярсып кага —
Яз—яз инде: һәркем яшәрә.
Гомер алып килә,
Картлар аны белә.
Сөю назын бирә яшьләргә.

Дәрт өстәп яшәргә,
Табигать яшәрә —
Язларны мин сөям, табынам.
Шушы язлар белән
Сөюләрем килгән —

Язмыш ярым язда табылган.

Кар сулары аксын,
Кошлар канат каксын,
Язлар килсен безнең якларга.
Язмышларны җиңеп,
Бар газапка түзеп,
Сөюләрне кирәк сакларга.

САГЫШЛАРГА ТҮГЕЛ ТҮЗӘРЛЕК

Таң кошлары сайрар...
Миңа сердәш алар —
Моңнарымны илтер һәр иртән.
Еллар узып та мин
Әгәр кайтмыйм икән,
Каршы чыгып һаман көт, иркәм.
    Сөюләрең, иркәм,
    Керсез, дөрес икән —
    Кайтмыйча соң ничек калырмын.
    Сагышларга түзми,
    Яннарыма килсәң,
    Юлга чыгып каршы алырмын.
Тик мәңгегә кил син,
Кояш кебек көл син,
Күңелеңдә булсын гүзәллек.
Очып кайтам үзем,
Бәгърем, кара күзем,—
Сагышларга түгел түзәрлек.

ТӨШЕНКЕЛЕК

Ник юксынам икән үткәннәрне,
Белмим, нигә ярсый йөрәгем?
Әллә инде гомерем чиге җитә,
Әллә тиккә яшәп йөргәнмен.

Их, юксынам яшьлек елларымны,
Кайтарып ла булмый кирегә.
Кире кайтмый,
Беләм.
Яшьлегемне
Төшләрдә гел риза күрергә.

Гел юксынып, җаннар гел кыйналып,
Гомерләрем шулай үтәрме?
Түзсә түзәр икән бу йөрәк тә —

Күпме газапларны күтәрде.

Нишләргә сон? Җаннар сыкрап елый.
Яшьлек, кая таба юл алдын?..
...Гомерләрнең кара урманына
Үкси-үкси кереп югалдым...

АКЛЫК
Ап-ак карлар яуган таң атуга
Җилләр исми. Рәхәт. Һава тын.
һәрбер йортта учакта ут яна
Торбалардан чыга ак төтен.

Ак карларга һич басасым килми —
Тап төшерермен күк күренә.
Эзләр салсам әгәр, шул карларда
Керләр кунган кебек күңелгә.

Төтен дә ак, яуган карлар да ак,
Күңел дә ак әле бүгенгә.
Бүген генә түгел, күңелкәйләр
Ап-ак булсын иде гомергә.

КЫШ
Такыялар үреп йөргән болын
Кар астында калган күмелеп.
Тал-тирәкләр мамык шәлен бәйләп
Елга-кызга карый иелеп.

Җиләк җыеп йөргән тау буйлары
Ак тынлыкка чумып калганнар.
Аландагы түгәрәк күлләр дә
Кышкы озын уйга талганнар.

Нинди садә, нинди гузәл дөнья!
Ап-ак карлар күмгән галәмне...
...Кыенсынып торам, йөрталмыйча
Ак кәгазьдән кара каләмне.

ЧӘЧӘКЛӘРЕН КОЯР ГӨЛЛӘРЕМ
Сине күрсәм үзем,
Ала алмыйм күзем.
Сихерлисең, ахры, син мине.
Сиңа җырлар тездем,

Сөйдем, әйтми түздем,
Ник килмисең, иркәм, син бире.

Сиңа тарта күңел, һич түзәрлек түгел,
Каршыларга сине гел барам.
Сүрел, димен, сүрел —
Юк, сүрелми күңел,
Сөюемә тугъры мин калам,

Узар шулай еллар,
Туар яңа җырлар,
Кабатланмас узган көннәрем.
Сине көтә-көтә,
Яшьлек узып китә —
Чәчәкләрен кояр гөлләрем.

САУМЫ, ТУГАН ҖИРЕМ

Саулармы сез, туган як кырлары!..
Кайтам сезгә, кайтам кайгысыз.
Изге җирсез — туган яктан башка
Яши ала, әйтче, кайсыгыз.
        Исәнмесез, яшел тугайларым,
        Атлар көткән иркен болыннар?
        Һаман сездә балачактагыдай,
        Чабып йөри икән колыннар.
Ни хәлләрдә, авыл агайлары,
Исәнмесез, әби-апалар.
Туып-үскән җирен ташлаганнар
Саргаешып кире кайталар.
        Саулармы сез, туган-тумачалар,
        Исәнмесез, күрше-күләннәр!
        Туган якларына ашкындылар
        Чит җирләрдә яшәп үлгәннәр.
Ә мин кайтам, нык-нык басып кайтам
Сине сагынып, яшьли торган җир.
Син гомергә яшә, анам кебек
Иң кадерле, садә, туган җир...

ӘНКӘЕМ

Йөрәк үкси, сыкрап елый йөрәк,
Кочам, бәгърем, кабереңне.
Кичер, әнкәй, ахры белалмадым
Исән чакта кадереңне...
Кабер ташындагы язудан

Кабереңә киләм, башым иям,
Гел син генә , әнкәй, уемда.
Исләремдә, бәхет теләп безгә,
Кайнар итеп үптең,туемда.

Шул үпкәнең, әнкәй, бүгенгәчә,
Җылы итеп тора күңелне...
...Сагышларым дәрья-диңгезләрдәй,
Күз яшьләре булып түгелде.

Ниләр эшлим, бик сагынам сине,
Үзәкләрем , әнкәй , өзелә.
Дөньялыкта бернәрсә дә минем
Күренмидер һич тә күземә.

Киткән чакта бәхиллегең куйдың –
Күз алдымда әле бүген дә.
Шул мизгелләр кайнар утлар сыман
Гел яндырып тора күңелдә.

Мин терелтер идем, әнкәй, сине,
Ул эш килсә әгәр кулымнан.
Каберташка йөрәк җылым бирәм,
Бүләк булсын төпчек улыңнан...

МОҢ

Тыңладым мин иртән, таң алдыннан
Бер моңлы җыр,
Тын да алмадым.
Ераклаша барды, мин дә киттем
Моң артыннан
Һич тә калмадым.

Алып китте ул моң урманнарга,
Кәккүкләргә кушылып җырладым.
Моң җәелде иркен болыннарга,
Чәчәкләрнең моңын тыңладым.

Басу-кырлар моңны отып алып,
Башакларга бүләк иткәннәр.
Башаклардан таң җилләре отып,
Тәрәзәмә элеп киткәннәр.

Тыңладым мин иртән, таң атканда
Тәрәзәмә сарган моңнарны.
Беркайчан да, һич тә онтасым юк
Шул моңнарга тиңдәш таңнарны.

ЯШӘРГӘ ДӘ ӘЛЕ ЯШӘРГӘ.

Гомерләрне айлар, еллар саный,
Саный аны сәгать, минутлар.
Гомерләрдән озын ниләр бар соң?
Гомерләрдән кыска нәрсә бар?

Гомер берәү, икәү түгел гомер,
Яшеннәрдәй кирәк яшьнәргә.
Шул гомернең кадерләрен белеп
Яшәргә дә әле, яшәргә.

Ай, белмибез кадерләрен аның,
Йөгереп кенә үтеп китә ул.
Йөзебезгә җыерчыклар сала,
Чәчебезгә чаллар кертә ул.

Көйләрнең дә моңы бетеп бара,
Кешеләрнең дә көче югала.
Нәрсә булды икән бу гөлләргә?
Нәрсә булды икән дөньяга?